Once a close relative that I used to visit once in a while found out about my diagnosis. I went out for a walk or something, and somehow she got interested in the contents of my bag. She found my pills there, googled the name, and easily understood everything. When I came back I found my bag by the door, while everyone was busy cleaning the house. To my question she replied brusquely, "You see, I have children, and your disease is like a wall-eye... Forget our address!" That day there were tears of resentment and the suicide thoughts that I was growing accustomed to. The ruins of my life were rocked again by a cruel hurricane destroying everything. The resentment was even more bitter due to a fact that my relative never gave me a chance to explain anything, and we have not been talking ever since.

But, as I said, there is sadness, and there is joy.

## POSITIVE MEMORIES

Since my first university days I got to like a girl from my group. Soon we became close friends – we had many things in common, but not so much as to bore each other. We felt good together, but by the end of the first year I was diagnosed with HIV. Even in this relationship my fear dominated, I was afraid to scare her, and I began to move away. Soon we were just school friends, and the relationship boiled down to saying hi.

I still liked her, but I couldn't even think that she finds out – so every time she tried to learn, to ask me what's wrong – I simply began to avoid her.

When we were in the second year there was this interesting situation: we had an immunology class, and as we discussed HIV I couldn't contain myself and asked the other students as to what their reaction would be if their boyfriend or girlfriend was found out to be HIV-positive. Their answers – despite me awaiting them anxiously – were predictable. No, no way, nobody would want to share their lives with an HIV-positive person.

But there was this beautiful moment – the girl I liked so much suddenly replied that HIV was no reason for breaking up a relationship. She said it was not strong enough challenge for the serious feelings.

I still remember how I blushed and smiled, and a fragile idea to disclose my secret to her stayed with me ever since. Oh how many times I visualized her reaction remembering her opinion regarding HIV and relationships, but I still needed two years to to gain all my courage and tell her about my status. I invited her to meet me "for the old times' sake" and by the end of that day I proposed that we dated. That's when I told her I was HIV-positive. Her reaction was a revelation to me. She was almost not surprised at all. She took it calmly and asked one single question – did I avoid her throughout these years only because I didn't want to tell her about my disease? And when I said yes, she laughed. Of course she guessed everything from the moment I asked that question at the lecture. We've been dating for a third year now, and it's our plan to get married next year, in 2017. She's my support and my foundation. After I found her my life has become so much easier.

I am also grateful to the Almighty for the day I gathered all my courage and went to a self-help meeting for the people living with HIV. They kept inviting for two years, but I thoroughly avoided that. After the very first day in the group I realized I wasn't alone. Not alone! Slowly my participation grew more and more active, and I hardly noticed how I became the nucleus of the group. I began to work as a consultant, and in order to perform duly I read a lot and collected as much evidence based information as possible – my being a medicine student just made it even more interesting. My speaker talents came of use as well. That's how my way began – from a consultant to the chair of the patients' council of the Umit public organization under the local AIDS center. The days of my recluse were over, I began to get involved in public life. Both the regional and the national association of the people living with HIV were a great support. Such associations really help people like I to deal with the fear often piercing our entire lives. That's how I enrolled in the course of the EATG Training Academy STEP – UP.

I began to enjoy life. I no longer fear my status. I believe I am using it for the benefit of myself and the others. Thanks to HIV I became of use to people – I train, I conduct seminars for the HIV prophylactics, I work to enforce unity of the people living with HIV in my region. Today I have big plans, I want to create, and help people, and live a long and happy life!

When I began working as a consultant I discovered a joy of socializing with people, and I do it with pleasure ever since. Each story is an experience related to pain, tears and losses. I remember that pregnant girl who came to me facing this terrible choice – due to her extremely weak immune system the doctors insisted on abortion (she was 12 weeks pregnant), and after reading all those various internet forums she was left dumbfounded. And she was scared, too. Her mind and the doctors told her she should give up her baby, but something inside did not let her do it, she was keen to keep the baby and become a mother. Together we began to go through various recommendations, I organized an education session for her, personally spoke to the doctor who recommended abortion – and found out that all his reasons and arguments were unfounded guesses. He simply shied away from responsibility, and didn't want to share it with the young woman. Fortunately, she made a decision against the abortion, and I was helping her for some time. Due to various circumstances we lost track of each other, I heard this and that from the self-help group members, but the

contact really was lost. Then all of a sudden I met her by accident in the AIDS center building – and she wasn't alone. She had a little daughter with her, and oh she changed so much! It was amazing to see her so happy. The little girl's records were written off – she did not have HIV.

I was happy for them – both as a doctor, and as a man who had overcome fear and learned to be happy.

# Afterword

Different faces. Different fates. On the one hand, there is nothing common between them. Almost. In the normal circumstances they would hardly find equally interesting topics for conversation. Nevertheless, something made them – people living hundreds and even thousands of miles away from Kazan – to get together here on 15 May 2016. Not the money. Not the hunger for fame. Not the boredom. They formed the starting line of the Kazan Marathon 2016 "with open faces" on the International Candlelight Memorial Day in order to make a statement – **HIV-positive people are no different from others.**

Some of these people have been concealing the truth about their status even from their families and friends for years. The only reason for that was the fear of judgment and discrimination. Try to think, is there a prejudice or intolerance in your own attitude towards the HIV-positive people today?

We hope that the stories you have read will help you redefine your attitude not only to the HIV positive people, but also to your own health.

***Genuinely wishing you all the best and new achievements,***
***ANO "Center for Advanced Healthcare Technologies"***

# Conclusion

The history of HIV encompasses 35 years, and in early 2016 Russia registered its 1,000,000'th case of HIV infection. For a long time, HIV struck mostly narrow population groups – drug users, sex workers and men having sex with men, but lately the virus has creeped into all layers of our society.

I won't be surprised at all if half of the young and socially active readers who spent their time reading this book would say, "Well, this one is not going to happen to me." Right? Congratulations! After you're done reading these stories, please think – do these people correspond to the image of the HIV-positive people often imposed on us by the stigma, born out of the ignorance and fear?

I am writing this with only one purpose – please TEST YOURSELF – by regularly taking HIV tests. Once every six months. For the sake of your own health.

***V. V. Pokrovsky***
Head of Federal Scientific Methodical Center for AIDS Struggle and Prophylactics



# Conclusion

In the recent years the rate of growth of the new cases of HIV infection in the Republic of Tatarstan has been continuing. The regular testing practice called for by the members of the TEST YOURSELF team from the pages of this very timely published book is one of the preventive measures against the spread of HIV. Tatarstan began increasing the scale of testing 15 years ago, when HIV-infection intensified, especially in the high risk groups of population.

The city of Kazan is solidifying its role as a capital of the highest level sports events, which is a good driver for the launch and development of new healthcare technologies. It was in Tatarstan that major sports competitions became the ground for HIV prevention and testing. During the World Student Games 2013 and the World Aquatic Championship 2015 various HIV prevention approaches were tested among the athletes and spectators.

I am very pleased that this wonderful trend is further continued in 2016 by the Kazan Marathon. This event is yet another proof of the efficiency of the partnership between various sectors of the society, which has been implemented in the Republic of Tatarstan for years. Thanks to the joint collaboration the chances for the radical prevention the spread of HIV infection in the republic are becoming higher.

***N. I. Galiullin***
Head of the Republican Center for AIDS and Infectious Diseases Prevention and Prophylactics under the Ministry of Healthcare of the Republic of Tatarstan

# Татар телендәге версия

# Сәламләү

Гадәти булмаган бу китапны укучыларны сәламлим. Дөньяда ВИЧ инфекция диагнозлы шактый кеше билгеле. Соңгы елларда күп кенә танылган кешеләр үзләренең уңай статуслары турында сөйли башладылар, шул исәптән безнең илдә дә.

Кеше иммунодефициты вирусын беренче тапкыр тикшергән вакытлардан соң утыз ел вакыт узды. Шул арада җәмгыять ул кешеләргә төрлечә мөгамәләдә иде.

ВИЧ-инфекция турында белмәү, алдан ук тискәре фикер йөртү һәм бозык күзаллаулар аркасында, стигматизация (дискриминацияләү) төшенчәсе барлыкка килде. «Стигма» сүзе грек теленнән алынган һәм «каргыш» дигәнне аңлата. Бүгенге көндә бөтен дөнья ВИЧ-инфекциянең эпидемик үсеше шартларында яшәгәндә, ВИЧ авырулы кешеләрне дискриминацияләү шактый кискен проблема булып тора. Шик юк: кешеләргә хас кайбер күпсанлы хорафатлар белән бергә андый дискриминацияләүнең төп сәбәбе — тиешле мәгълүматның булмавы. Югыйсә ВИЧ авырулы кешеләр — гап-гади затлар. Хокуклары да ВИЧ инфекциясе булмаган кешеләрнеке кебек үк. Алар арасында күп яхшылыклар эшләгәннәре дә, берничек тә дан казанмаганнары да, танылганнары да, илебезнең гап-гади гражданнары да бар. Нәкъ менә шуңа күрә ВИЧка бәйле дискриминацияләү һич рөхсәт ителми.

Без 2016 нчы елның 15 нче маенда Казанда төрле-төрле илләрдән килгән ВИЧ авырулы йөгерешчеләр белән бергә йөгерәчәкбез. Аларның күбесе тулы канлы тормыш алып барып кына калмый, 42 километр араны йөгереп тә уза ала. Бу йөгерү безне берләштерәчәк. ВИЧ авырулы йөгерешчеләрнең башкалардан аерылып тормавына ышанырга мөмкинлегебез булачак.

ВИЧны дәвалау өчен, дарулар әлегә кадәр юк, әмма ВИЧ авырулы кешеләрнең яшәешенә ярдәм итү чаралары чагыштырмача югары дәрәҗәдә. Алар СПИД үсешен туктатып торалар.

Илебез гражданнарын мәгълүматлар белән таныштыру эшен дәвам итәчәкбез һәм тагын да арттырачакбыз. «Үзеңне Тикшер» дип аталган 2016 нчы елгы Казан марафоны кебек чараларның тырышлыкларыбызны тулыландырып торуы шатландыра.

***А. Ю. Попова***

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсен күзәтү буенча Федераль хезмәт җитәкчесе, Россия Федерациясенең баш санитар табибы



# Сәламләү

Кешелек тарихында аралашу һәм шәхесара тәэсир итешү культурасының әле беркайчан да Интернет гасырындагыдай үзгәреше белән очрашырга туры килмәгән иде. Интернетның кеше культурасына тәэсире темасына тирәнтен кереп тормыйм, әмма менә бәхәссез бер факт. Хәзерге заманда кешеләрне аера торган берничә билге барлыкка килде: Интернет, смартфон, планшет һәм ноутбуклар. XXI гасырга кадәр алар безгә хас түгел иде. Бүгенге көндә нәкъ менә шулар җәмгыятьнең мәдәниятен формалаштыралар, ә аларның булмавы исә күпләр тарафыннан артта калганлык билгесе буларак бәяләнә!

Шулай итеп, бүгенге яшь һәм иҗтимагый яктан актив Россиялеләргә мөрәҗәгатем шул: ВИЧка даими тикшерелеп торыгыз. Ярты елга бер тапкыр тест ясатыгыз һәм Интернетка (Facebook, ВКонтакте, Twitter, Instagram һәм башкалардагы аккаунтларыгызда) тест ясатуыгыз турында мәгълүмат урнаштырыгыз. Әлеге мәгълүматны даими яңартып торыгыз. Башкаларның да сезне хуплавына ышанам. Бу исә ВИЧка даими тест ясатып тору культурасын булдыруда ярдәм итәр. Менә шул вакытта чыннан да заман белән бергә атлыйбыз, без — ватанпәрвәр һәм илебездәге яшь буынның киләчәге турында уйлыйбыз дип әйтергә мөмкин булыр.

Бераз күбрәк аңлыйсыгыз киләме? Ни өчен? Бу басмадагы бәяннарны укыгыз. Алар үрнәк булырлык.

***Г. Г. Онищенко***

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе ярдәмчесе

# Сүз башы

Бу басма турында фикер 2015 елның көзендә, башлангычыбыз Казан марафоны директоры Вадим Янгиров мисалында спорт җәмәгатьчелеге, дәүләт хезмәткәрләре – Россия кулланучылар хокукларын яклау һәм күзәтчелек итү комитеты башлыгы Анна Юрьевна Попова, РФ Хакимияте Рәисе ярдәмчесе Геннадий Григорьевич Онищенко һәм Татарстан Республикасының югары дәрәҗәдәге җитәкчелеге – Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов тарафыннан яклау тапкач туды. Нәтиҗәдә, Республика тармак министрлыклары һәм коммерциячел булмаган оешмалар арасында 2016 елда ҮЗ-ҮЗЕҢӘ ЫШАН иҗтимагый кампаниясе яклавы астында Казан марафонын уздыру турында килешүгә кул куелды.

Россия спорты һәм сәламәтлекне яклау тарихында беренче мәртәбә марафон стартына уңай ВИЧлы йөгерешчеләр командасы «ачык йөз белән» чыгачак. Казанда 2016 елның 15 маенда, СПИДтан үлүчеләрне халыкара искә алу көнендә, һәркайсыбызга ВИЧ-инфекциягә тест үтүнең мөһимлеген искәртү, ВИЧның аерым төркем кешеләр – наркоманнар, секс хезмәте күрсәтүчеләр һәм гей-җәмәгатьчелек проблемасы гына булу турындагы мифны юкка чыгару өчен, ҮЗ-ҮЗЕҢӘ ЫШАН командасы әгъзалары профессионал җиңел атлетлар, сәяси эшлеклеләр, артистлар һәм сәламәтлекне саклау иҗтимагый системасы хезмәткәрләре белән иңгә иң стартка басачак.

Без бу китапта кешеләрне «алдан билгеләнгән» параметрлар палитрасы буенча җыярга омтылмадык. Без бары берничә дистә бәян арасыннан хезмәттәшләребезгә, туганнарыбызга һәм якыннарыбызга – ВИЧ турында бик үк мәгълүматлары булмаган кешеләргә кызыклы тоелганнарын гына сайлап алдык. Сез бу китап битләрендә инде күп еллар «ачык йөз белән» яшәүчеләрнең һәм иммунитет кытлыгы вирусы белән дөньяга килергә насыйп булганнарның тавышларын ишетерсез. Әле тагын әти-әниләренә үзләренең уңай ВИЧлы булулары турында марафон старты алдыннан гына сөйләргә карар биргән кешеләрнең тарихларын табарсыз. Бу гаҗәп, һәм ул безнең бергә эпидемияне туктата алуыбызга зур өмет уята.

Безнең башлангычыбызга, бу басманың чыгуына теләктәшлек күрсәткән барлык кешеләргә, әлбәттә инде күп мәртәбәләр тормышның төрле өлкәләрендәге яңалыкларны яклап чыккан кунакчыл Татарстан Республикасына чиксез рәхмәтләребезне җиткерәбез.

***«Сәламәтлек саклау өлкәсендә алдынгы технологияләр үзәге» автономияле коммерциясез оешма***

# 01

# Деанна

## Австралия

46 яшь, дистанция 42 км



Озак еллар дәвамында мин «ачык йөз» белән яшим. Курку эчендә яшәү миңа беркайчан да ошамады. Тормыш юлыннан алга бару, һичнәрсәдән курыкмау һәм кешеләрнең күзләренә кыю карау мөһим бит. Нәкъ менә шулай яшим дә инде мин.

Танылган спортчылар, кагыйдә буларак, һәрвакыт матбугат үзәгендә. Ә бу исә миңа ярдәм итте: спорт дөньясында танылган булуым аркасында үз тормышым турында гына түгел, ВИЧ авырулы башка атлетларның тормышлары турында да вакытлы матбугат чараларында уртаклаша алдым.

Мондый тәҗрибәнең башкаларны үз-үзенә ышаныч белән коралландыра һәм тормышларында уңай үзгәрешләргә өмет уята алуын төгәл беләм. Мин шуңа ышанам: хәтта ВИЧтан ерак торган кешеләр дә бу авыру турында күбрәк белү мөмкинлегенә ия булалар. Бу исә бик мөһим, ул бөтен кешегә кагыла бит.

Минем ирем ВИЧ авырулы түгел, безнең ике балабыз да бу авырудан башка яши. Аларга 12 һәм 17 яшь, алар спорт белән актив шөгыльләнәләр.

Иң элек үзем турында сөйлим. Мин үземнең ВИЧ авырулы икәнемне 1994 нче елда, 24 яшемдә Лондонда белдем. Ул вакытларда мин күп сәяхәт итә идем, әмма Англиягә мине сәламәтлегемнең какшавы алып килде. Яхшы табибларга эләгергә өметләндем мин. Ул вакытларда Австралиядә ВИЧ-терапия даруларын табып булмый иде. Биш ел яши алсам, бу даирәдә минем «озак яшәүче» булып саналачагымны әйтүләрен әле дә хәтерлим.

22 ел узып китте. Хәзер инде миңа 46 яшь. Минем көчем ташып тора, сәламәтмен һәм физик яктан үземне бик яхшы хис итәм. Бүгенге Австралиядә ВИЧ-инфекцияне дәвалаучы дарулардан, сәламәтлекне саклауның нәтиҗәле системасыннан файдалану мөмкинлегем булганга мин чиксез рәхмәтлемен.

ВИЧ-инфекциянең адәм кыяфәтле булуы турында кешеләргә сөйләү бик мөһим минем өчен. Мин һәммә кешегә дә ачык. 18 ел дәвамында күп төрле кешеләр алдында даими чыгыш ясыйм: укучылар, табиблар, шәфкать туташлары, дару ясаучы компанияләр, төрле клублар, хатын-кызлар оешмалары һәм корпоратив берләшмәләр. Әлеге еллар аралыгында Австралия парламентында, шулай ук берничә халыкара конференциядә чыгыш ясавымны искә төшереп узу да мөһим дип уйлыйм.

Үзеңнең шәхси тарихың белән уртаклашу мөмкинлеге – бик куәтле корал.

### ДИАГНОЗДАН СОҢГЫ ИҢ БӘХЕТЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

Мин бик ачык һәм бай эчтәлекле тормышта яшим, искиткеч истәлекләрем күп, шуңа күрә иң шатлыклыларын сайлап алу минем өчен авыр булмады.

**1. Тиа-Рэй исемле кызымның туувы.** Диагноз куйганнан соң, бала таба алмаячагымны шактый катгый итеп әйткәннәр иде. Нигездә, ул вакытта мин балалар турында уйламадым да. Ахыр чиктә, миңа 24 яшь, ә күп дигәндә биш ел гомерем калган иде. Шулай да, әлеге сүзләрне ишеткәч, мине тирән кайгы хисе биләп алды. Кисәк кенә үземнең балам булмаячагын әрнеп аңлап алдым. Шулай булса да, күпчелек хатын-кызда аналык хисе бик көчле. ВИЧ беренче көнне үк минем ана булу хокукымны тартып алды.

Ул елларда, уйнап йөрүче балаларны күзәтеп, парктагы эскәмиядә сәгатьләр буе утыруымны хәтерлим. Тыныч кына елый идем мин, ә күңелемдә бушлык хөкем сөрә иде.

Әмма тормышта бик шәп бернәрсә бар - фән. Ул яшәеш һәм өмет бүләк итә. Акылга сыймаслык теләкләрне һәм хыялларны да ул чынбарлык итә ала.

Австралиядә вируслы инфекцияләрне дәвалау 1996 нчы елда гына барлыкка килгән. Тормыш кинәт килеп керә торган үлем чүлен күз алдына китерегез әле. Миңа бәхет елмайды: организмым даруларны җиңел кичерде. Кан тамырларымда тормыш гөрли башлады, һәм мин үземнең киләчәгем буласына тагын ышандым.

Тагын ике ел узып китте. 1998 нче елның 11 нче маенда мин искиткеч һәм бар яктан камил кыз бала таптым. Берничек тә өметләнә алмаган бүләк – менә ул, мин аны үз кулларымда тотып торам. Чынга ашкан хыял.

Нәрсә дә булса турында хыялланырга да ярамаганда, тормыш вакыйгалары бигрәк тә чынга ашмас сыман тоела. Соңыннан исә син аларны гамәлгә ашыру өчен мөмкинлекләр табасың. Хәзер кызыма 17 яшь. Әле минем тагын 12 яшьлек улым бар.

**2. Кияүгә чыгу.** ВИЧ-инфекция диагнозы хатын-кызны еш кына сөйкемсез, кимчелекле, кадерсез, акылсыз, тиз рәнҗи торган, югалып калгандай, файдасыз бер кеше итеп тоярга мәҗбүр итә. Синең диагнозыңны белеп алып тикшерә башларлар дигән курку яшеренергә һәм качкан урыныңнан чыкмаска мәҗбүр итә. Статусыңның билгеле булуы – зарурлык, әмма иң куркынычларының берсе.

**Һәммә нәрсә дә әлеге вируска караган билгеләр җыелмасының колачына бәйле. Романтик мөнәсәбәтләр мөмкинлеге турындагы фикер баштарак тормышка ашмастай булып тоела. Башта бер генә сорау бөтерелә: әгәр булса, әгәр булса, әгәр булса...**

Башта мин гомумән шәхси мөнәсәбәтләр теләмәдем. Сәламәтлегем кебек үк тормышны да начар һәм көтелмәгән нәрсәләрдән тора дип күз алдыма китердем. Йогышлы авыруларны дәвалый торган даруларның барлыкка килүе максатларымны һәм хыялларымны үзгәртте.

Беренче очрашуда ук Австралияле Питерга – ВИЧ авыруы булмаган егеткә үземнең диагнозым турында сөйләгәч, ул күзен дә йоммады. Минемчә, очрашудан соң ул шактый озак Интернетта нечкәлекләрен өйрәнеп утыргандыр. Шуннан соң икенче очрашу, өченче, дүртенче... Берничә сорау яңгырады, тик бернинди курку, һичбер нәфрәт тойгысы, һичбер нинди битарафлык булмады...

Туй көнебездә Питер янында басып тору – бөтен тормышымның иң бәхетле мизгелләренең берсе. Мине ничек бар шулай ярата торган ирнең кулларын тотып тору... Минем хыялларымны уртаклашып кына калмыйча, тагын күп нәрсәләрне ялкынланып гамәлгә ашырырга омтылучы ул. Туйга безнең барлык туганарыбыз һәм дусларыбыз килде.

**3. Adventure Race[1] спортында җиңү.** Әти-әниләрем спорт белән шөгыльләнүемне кечкенәдән үк хуплап килделәр. Яшүсмер вакытымда ук мин триатлонны сайладым. 14 яшемдә беренче зур ярышта катнаштым һәм беренчелекне алдым. Җиңүләрем дәвам итте: башта мин Австралия чемпионы булдым, соңрак яшьләр арасында дөнья чемпионы исемен яуладым. 1990 нчы елда Дуслык Уеннарында мин Австралия өчен ярыштым. Бу спорттагы иң күренекле уңышларымның берсе булды.

Диагноз җиңүләремне күз ачып йомганчы туктатты. Бу хәлләр сәламәтлегемнең кисәк какшавы шартларында килеп чыкты.

Соңыннан 36 яшь вакытта маҗаралы йөгереш турындагы белдерү күземә ташланды. Максатым барлыкка килде. Хатын-кызлар беренчелегендә җиңәргә теләдем. Һәммәсе дә килеп чыгасына бик нык ышандым.

**Җиңү теләгем беркайчан да сүнмәде. ВИЧ атлы көндәшем белән көрәшү өчен, миңа көч биреп торды.**

Беренче маҗаралы йөгерештә хатын-кызлар беренчелегендә мин җиденче булып килдем. Шуннан соң миннән чын күңелдән бирелгәнлек һәм яңа бурычлар таләп итә торган шөгыльләнүләр башланды. Алдагы елда 37 яшьтә мин Австралия чемпионатында күп көрәшнең бу төрендә хатын-кызлар арасында беренче урын алдым.

Финиш сызыгын узганда, мин кинәт җанатарлар тавышы арасында туганнарымның тавышын да ишеттем. Якыннарым көтелмәгән бүләк ясарга теләгәннәр һәм минем өчен җан атарга килгәннәр икән. Әлеге берничә секунд хәзер дә горурлык хисе биреп тора.

Шул вакыттан һәммәсе дә ачык аңлашыла башлады. Теләгәнемә ирешә алуымны аңладым. ВИЧ миндә яши, әмма ул мине яшәргә өйрәтми.

## ДИАГНОЗДАН СОҢГЫ ИҢ ӘРНҮЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

Тормышымда әрнүле мизгелләр булды, әмма аларның барысы да ВИЧ инфекция белән турыдан-туры бәйләнмәгән иде. Актив яшәү һәм дөрес караш аркасында ВИЧ инфекция ниндидер бер гап-гади тирәлек кенә булып калуына тулаем ышанам. Аның турында онытырга ярамый, тик шулай да ул - бары тик гап-гади тирәлек.

**1. Әти-әниләреңә дөреслекне әйтү.** Иң якын кешеләреңә диагнозың турында дөресен сөйләү бер дә җиңел түгел, бигрәк тә диагнозны кую белән. Бу вакытта синең хисләрең тышсыз тимерчыбыкларга охшап кала.

1 Күп ярышның бер төре – йөзү, байдарка, тау велосипеды һәм йөгерү

ТАТ 01

Әти-әниләрем белән сөйләшү бик авыр булды. Диагнозны Англиядә куйдылар, мин Австралиядәге әти-әниләремә шалтыратмадым. Моны миңа күзгә-күз карап эшләргә куштылар. Андый яңалыкларны, чыннан да, телефоннан хәбәр итмәскә кирәк. Кыскасы, үземнең авыруымны белгән көннән әлеге сөйләшүгә кадәр бер ел узып китте. Иң элек әниемә сөйләргә булдым. Әйтегез әле миңа, әнигә мондый хәлне ничек сөйләргә соң?! Сөйләгәндә, аның әрнүен, сүзләремә аның мөнәсәбәтен күргәндә, исәпсез-хисапсыз сорауларга җавап биреп, аны тынычландырырга тырышканда, тормышымдагы иң авыр көннәрнең берсен кабаттан хәтеремдә яңартканда, өзлексез әрнүемне хәтерлим.

Әти белән сөйләшергә кыюлыгым җитмәде. Әниемнән үтендем.

**2. 2005 нче ел. СПИД.** 2004 нче елда безнең икенче балабыз Занда туды. Шуннан соң мин дарулар эчүемне туктатып тормакчы булдым. Әзрәк тын алырга. Үземнең халәтемне бик ачык хәтерлим. Булды, җитте, башка кирәкми бу миңа. Үземне җиңелмәс итеп хис иттем.

Дөреслек шунда: ВИЧ боларны гафу итми.

Әкрен-әкрен минем иммун системам көчсезләнә башлады. Хәлемнең начарая төшүен һәм начар хәл-әхвәлемнең билгеләрен игътибарсыз калдыра бардым.

Нәтиҗәдә - мин хастаханә палатасында. СПИД. Үпкә ялкынсынуы.

Ничек курыкканымны үзем генә беләм! Балалар бик курыкты! Кызымның рактан үлүемә ышануын мин соңыннан гына белдем. Ул вакытта барлык чәчләрем коелып бетте. Инде җайланган гаилә тормышында әни кешенең булмавы һәрвакыт бик авыр кичерелә.

Бу тәҗрибә мине күп нәрсәгә өйрәтте. Әгәр ВИЧ-инфекциягә хөрмәт белән карамасаң, үлем белән бик якын очрашуыңны көт тә тор. Инфекциягә каршы дарулардан башка организмымның никадәр тиз бирешүчән һәм зәгыйфь булуын бик төгәл үзләштердем.





Дәвалануга бәйле тәҗрибәләрне башка беркайчан да уздырмас өчен, көчемнән килгәнен барысын да эшләргә карар бирдем.

Минем тарихымны укырга вакыт тапканыгыз өчен, барыгызга да рәхмәт.



ИКЕНЧЕ БӘЯН

# 02

# Яна

Украина

18 яшь, дистанция 3 км

Минем исемем Яна. Мин Киевтан. Миңа унсигез яшь.

Ун яшьлек чагымда әнием миндә ВИЧ икәнен әйтте. Миңа бу инфекция туган вакытта эләккән. Мин моның белән бирелгән гомерне яшәргә тиеш. ВИЧ белән авырганда "күпме яшәп була" соравы гел "яңгырый".

Миңа әле ун гына яшь иде. Кинәт кенә өстеңә төшкән мондый авыр йөкне үзеңдә тоту мөмкин түгел. Икенче көнне үк мин бу турыда иптәш кызыма сөйләдем. Ул куркуыннан елап җибәрде. Үзенә миннән бу чирне йоктырды дип уйлады, ахрысы. Чөнки бер көн генә элек, без бер тәлинкәдән ашаган идек!. Мин аңа нәрсә әйтә ала идем соң? Ул вакытта үзем дә ничек яшәргә, нәрсә эшләргә кирәклеген юньләп аңлап бетерми идем әле.

Ун ел дәвамында мин үземнең авыруым турыда бернәрсә дә белмичә яшәдем. Барысы да искиткеч иде бит! Һәм кинәт… иң якын дустым мин сулаган һаваны суларга курка! Ләкин мин үземә бәхет елмайды дип саныйм! Дустымның әнисе, күп кенә уңай ВИЧлы кешеләрне белгәнгә күрә, дустыма минем авыруымнан тирә-якtагыларга бернинди дә куркыныч янамавын аңлатты. Ләкин… минем белән бер тәлинкәдән ашамавың хәерлерәк, әлбәттә. Бу кыз белән без бүгенге көнгә кадәр аралашып яшибез. Әйе, шулай килеп чыкты: мин үземнең статусым турындагы яңалыкны беренче ышанып сөйләгән кеше бүгенге көнгә кадәр янәшәмдә булды. Дус кызым мине ташламады.

Ләкин ВИЧ… ВИЧ. Каян гына миңа туры килде соң мондый бәла? Аңлый алмыйм. Төгәлрәге – ни өчен нәкъ миңа? Баштарак мин гел әниемне гаепләдем. Ул бит мине дөньяга китергән. ВИЧлы итеп тудырган. Кайвакыт, хәттә аны күрә алмавын турында да әйтә идем. Чөнки… минем туганнан алып шундый һәләкәткә дучар булуымда ул гаепле булмый, кем гаепле булсын?!

Әйе, мин әниемә "Сине күрә алмыйм!" дип әйтә идем, ләкин соңрак, әлбәттә, гафу үтенә идем. Яисә әйткәннәрне шаяртуга бора идем. Болар барысы да һәрвакыт кабатланып килде. Мин үземнең нинди начарлык кылганымны берничек тә аңлый алмый идем?! Ни өчен нәкъ менә миңа шулай язган?!

Шунысын исегездән чыгармагыз, мин әле бала гына идем. Тормышны тоя гына башлаган чагым. Һәм кинәт бөтен нәрсәне югалту куркынычы өстемә ишелде. Миңа нишләргә?

Вакытыннан алда үземне җирләүдән мине таяныч төркеме һәм лидерлык мәктәбе коткарып калды.

## Нәкъ шунда "Әгәр үлә калсам, мин ялгыз түгел" икәнлеген аңладым.

Мин "уңай" балалар һәм уңай ВИЧлы әти-әниләрдән туган балалар белән таныштым. Бу халәт "икелене сиңа гына куймыйлар, ә бөтен сыйныфка куялар" дип үзеңне юату белән бер иде…

## Мин үземнең япа-ялгыз булмавымны аңладым. Минем фаҗигамдә (ул вакытта ВИЧны зур фаҗига дип саный идем) гаеплеләр дә, хаклылар да булмавына төшендем.

Әти-әниемнең минем статуслы булуымда роле нинди булуга карамастан, яратуларына, мине беркайчан да ялгызымны калдырмауларына тагын бер кат инандым. Иң мөһиме – аларның янәшәмдә булулары. Шулай итеп гаиләбездә кабат гармония урнашты.

Әнием ВИЧ турында әйткәннән соң, мин терапия үтә башладым. Шулай хәзер сигез ел яшим, һәм тормышымда бернинди дә каршылык тоймыйм: минем яшисем килә, шуңа күрә көчемнән килгәннең барын да эшлим. Мин генә, бары тик үзем генә сәламәтлегем өчен җаваплы икәнен аңлыйм.

Шулай килеп чыты: мин хәзер тискәре ВИЧлы кешеләр белән күбрәк аралашам. Нишлисең, мин бервакытта да үземнең статусымны яшермәдем. Дусларымның "Менә безнең "уңай" кызыбыз да килде", дип шаяртуларына үпкәләмим, ә киресенчә шатланам гына. "Сәламәт" кешеләрнең ВИЧ турында белүләре, аларның моңа гадәти авыру итеп караулары, аны ниндидер хроник томау итеп кабул итүләре барыннан да мөһимрәк ләбаса! ВИЧ турында үзем нәкъ менә шундый фикердә. Башкаларның да шулай уйлавын телим. Чөнки мондый хәлдә бар нәрсә дә синең шәхси карашыңа, мөнәсәбәтеңә бәйле.

Үлем турында гел уйлап торсаң, ахыр чиктә, ул синең якаңа килеп ябышачак. Әгәр инде авыруны тормышның күптөрле якларының берсе итеп кабул итсәң, син яшисең. Бары тик бераз "башкачарак" кына.

ТАТ

02

Бу тәҗрибә мине күп нәрсәгә өйрәтте. Әгәр ВИЧ-инфекциягә хөрмәт белән карамасаң, үлем белән бик якын очрашуыңны көт тә тор. Инфекциягә каршы дарулардан башка организмымның никадәр тиз бирешүчән һәм зәгыйфь булуын бик төгәл үзләштердем.

Мин ни өчен Казан марафонында йөгерергә уйладыммы? Беренчедән, бу – минем өчен яңалык түгел. Бала чагымда ВИЧлыларга матди ярдәм күрсәтү өчен оештырылган бик күп марафоннарда катнаша идем. Кызганычка каршы мондый марафоннар Киевта инде берничә ел үткәрелми. Шуңа күрә бу чараны түземсезлек белән көттем. "Үзеңне сына" командасында йөгереп, мин бала вакыттан яраткан марафоннар атмосферасына чумачакмын. Зур кыюлык белән шунысын әйтә алам – бу минем 3 км га беренче "аңлы рәвештә" йөгерүем.

Ә тагын мин шунысына бик нык ышанам: мондый төр чаралар башка кешеләргә ВИЧ турында белергә ярдәм итә. Алар безнең хәлебез коточкыч икәнлекне, "уңайлардан" куркырга кирәклекне белеп кенә калмасыннар, ә безнең башка кешеләр кебек үк икәнлегебезне дә аңласыннар иде. Хроник томаулы кешене күргәч, беркем дә чукына башламый, шулай бит…

## ҮЗ ТОРМЫШЫМДАГЫ ИҢ БӘХЕТЛЕ МИЗГЕЛЛӘРНЕ СӨЙЛИСЕМ КИЛӘ:

**1. Үземнең статусым турында белгәч,** шок хәлендә калдым һәм күңелдә коточкыч бушлык барлыкка килде. Ниһаять, мин таяныч төркемендәге уңай ВИЧлы яшьләр белән таныштым. Үземнең ялгыз түгеллегемне аңлау – дөньядагы бар нәрсәдән мөһимрәк иде. Бу кешеләр белән мин әле дә дус яшим.

**2. Кечкенә вакытта әнием бик еш чит илгә китә иде.** Аннан башка бик күңелсез була иде, мин аның кайтуын зур түземсезлек белән көтә идем. Ул кайткан көн минем тормышымдагы "иң бәхетле көнгә" әверелә иде.

**3. Әгәр бәхет турында сөйләсәк,** мин үземне һәр секундта бәхетле кеше дияр идем. Һәрбер мизгел – ул бәхет, чөнки мин яшим. Бәхет өчен күпме генә кирәк соң? Кояш, китап, таулар, диңгез, яхшы кешеләр… Мин бәхетле кеше һәм бәхетле булу миңа бик тә ошый.

## ӘЛБӘТТӘ ТОРМЫШ АК БЕЛӘН КАРАДАН ТОРА. ХӘТЕРЕМДӘ АВЫР ҺӘМ САГЫШЛЫ МИЗГЕЛЛӘР ДӘ САКЛАНА:

**1. Миңа ун яшь.** Үземдә ВИЧ икәнлеген ишеттем. Ул вакытта ВИЧны дөньяда була торган иң куркыныч нәрсә дип саный идем. Ләкин соңрак шунысын аңладым: ВИЧ – ул минем кечкенә генә бер кисәгем икән бит. Әгәр миңа шуның белән дөньяга килергә язган икән – мин моннан берничек тә качып котыла алмыйм. Аның каравы, мин башка кешеләргә булыша алам. Миңа да кайчандыр үз статусымны кабул итәргә һәм башка уңай ВИЧлыларның хәленә керергә һәм аларның хөрмәтен яуларга ярдәм иткәннәр иде бит.

**2. Тормышымдагы икенче җитешсезлек – мәктәп.** Аны тәмамалагач, шунысын аңладым – унбер ел уку дәверендә мин бернәрсәгә дә өйрәнмәгәнмен икән. Чыннан да, синдә ВИЧ булса, синең тормышың… ВИЧсыз кешеләрнекеннән күпкә аерыла. Нәрсәнеңдер заяга узганын аңлау һәрвакыт авыр һәм күңелсез. Чөнки ВИЧ миңа тормышымдагы һәр мизгелнең кадерен белергә ярдәм итә. Һәм минем бер генә секундны да югалтасым килми… Мин бит яшәүне сайладым.

ӨЧЕНЧЕ БӘЯН

# 03



# Шон

АКШтан

35 яшь, дистанция 42 км

Казанда үз-үземне сынап карарга миңа Деанна Блегг тәкъдим итте, бу ханымны мин «чыдамлылыкка йөгерү» дә остазым дип атый алам. Мин Деаннага аның уңай ВИЧ статуслы булуы һәм ВИЧ белән яшәүче кешеләргә ярдәм итүе турында белгәч яздым. Миндә бер кочак курку хисе иде: уңай ВИЧ статуслы хәлдә ничек чыдамлылык ярышларында катнашырга? Аннары мин Деанна турында белдем, аның стигма (иҗтимагый тискәре кләймә) белән көрәшүен күрдем һәм миндә үземә ышаныч ныгый башлады. 2015 елның башында сәламәтлегемдә бик кискен чор кичердем, аңыма килгәч, шунда ук «World's Toughest Mudder[1]» узышында катнашу максаты куеп, һәр көнне шөгыльләнергә керештем. Бу узышта мин команда белән 40 миль (64 км) ара һәм 168 киртәне уза алдым...

**Казан марафонының «Үз-үзеңә ышан» командасында катнашып, кешеләргә бу авыруның мине беркайчан да туктата алмаячагын исбатлыйсым килә. Мин марафонда йөгерергә һәм бу тарихны язарга ризалаштым, чөнки, әгәр дә болар уңай ВИЧлы берәр кешене рухландырса яки аңа бернигә карамыйча көрәшергә һәм җиңәргә көч бирсә – мин әзер. Әгәр Үзәк бу китапта минем йөзем кемгәдер киләчәктә инфекция йоктырудан качарга ярдәм итәчәк дип санаса – мин шундый йөзләрнең берсе булырга риза.**

Ул җәйне, 2006 елны, тормыш үз көенә ага, барысы да яхшы кебек иде. Мин тырышып пешекче һөнәрен үзләштерә-үзләштерә, көненә сигез сәгать эшлим. График, әлбәттә, бик тыгыз, әмма мин ул җәйдә яңа гына диңгездән сәяхәттән кайткан һәм үземне ял иткән кешедәй хис итә идем. Бер-ике атнадан миңа егерме алты яшь тулачак...

Үземнең уңай диагнозымны белгән көн җиңеллләрдән булмады. Миңа клиникадан шалтыратып, анализларны яңадан бирергә куштылар, имеш, лабораториядә нидер булган. Мин коридорда утыра идем, шулчак кулларына ниндидер кәгазьләр тотып, гаиләбезнең күптәнге дусты булган доктор чыкты. Яныма килеп, янәшәмә утырды. Күземә туры карамаска тырыша-тырыша, кычкырып анализ нәтиҗәләрен укыды, ә үзенең тавышы әледән әле өзелеп китә. Мин анализларның ВИЧ-1гә уңай нәтиҗә биргәннәрен башта төшенеп җитә алмадым. Кинәт үземне бата башлагандай тойдым. Шул рәвешле мин статистиканы тулыландырдым.

Күземә яшьләр тыгылуын, докторның да миңа карап елавын, кайгы уртаклашу сүзләрен кабатлавын хәтерлим.

Моңа кадәр 26 ел эчендә безнең доктор ВИЧ инфекция белән зарарлану дәлилләнгән иң беренче очракта профессиональ рәвештә катнашкан булса, инде тагын менә шул вирус белән очраша – хәзер дусларының җиткән улларында... Ул миңа вирус ачылган көннән алып дәвалауның никадәр алга китүе турында ышануларын тәкрарлады, мин берникадәр вакыттан соң гына, торып, урамга чыгарга көч таптым. Өч километрлап ара узганмындыр, аннары гына юл читенә чыгып туктадым. Күземә яшьләр тыгылган, һәм мин аларга тулы ирек бирдем.

Үземнең тулысынча җимерелгән язмышымны җәлләп, ачы күз яшьләре түгеп утыруымны беркайчан да онытмам. Үзем белгән бердәнбер ВИЧ йөртүчегә шалтыраттым – аңа диагнозны бер ел чамасы элегрәк куйганнар иде. Ул очрашып сөйләшергә ризалашты. Без ниндидер бер урынга туктадык та берничә сәгать сөйләшеп утырдык. Ул моның һәлакәт түгеллегенә, минем әле киләчәгем барлыкка, һәм әлеге диагнозның менә дигән шеф-повар булу турындагы хыялларымның җимерелүен аңлатмавына ышандырырга тырышты. Ул вакытта һичьюгы бер кешегә ышану мөмкинлегем булуга мин бүген шатланып туя алмыйм. Минем үз хәлем турында теләсә кемгә сөйләп йөрергә җыенмаганлыгымны сез аңларга тиеш.

Минем дусларым һәм туганнарым бик күп, әмма мин үз хәлемне, өч иң якын дустымнан кала, барысыннан да яшерергә карар кылдым. Кызгандыру өчен түгел, бәлки үземнең радикаль пессимист булуымны белгәнгә, алар белән серемне уртаклаштым. Әгәр бик тирәнгә йомыла башласам, миңа саклану чарасы әзерләп куярга, минем арттан күзәтчелек итәрдәй кешеләр булдырырга кирәк иде. Физик сәламәтлек ягыннан түгел, күбрәк психик халәт нисбәтендә миңа нидер була-нитә калса – алар аны шунда ук сизәчәкләр. Үз-үземә кул салу турындагы уй минем башыма да килмәде, әмма җәзаның котылгысызлыгына шигем юк иде. Мин үз-үземә чокыр казыдым, һәм анда ялгыз гына төшәргә җыендым.

1 World's Toughest Mudder – команда белән чыдамлылыкка ярышу, ул дөньяда иң авыр узышларның берсе санала. Бу ярышта командалар 24 сәгать дәвамында, өзлексез рәвештә, чокырлы-чакырлы урында боҗра рәвешендә эшләнгән һәм төрле киртәләр корылган 8 км озынлыктагы полоса буйлап йөгерәләр.

Гәрчә булган хәлләргә тулысынча гаепле булмасам да, мин җаваплылыкның зурысы минем өстә икәнлеген аңлый һәм кабул итә идем. Презерватив кебек шулкадәр гади һәм арзанлы саклану чарасы куллануны катгый таләп итмәвем ахмаклык һәм гафу ителмәслек хатам булды.

Вакытлар үтү белән мин тагын берничә кешегә үземнең хәлемне сөйләдем, әмма гаиләмә түгел. Шушы көнгә кадәр – хәтта мин бу юлларны язганда да – минем зур гаиләмдәге бер генә кеше дә минем диагнозымны белми. Моның сәбәбе – чынбарлык белән йөзгә-йөз очрашудан, туганнарым миннән баш тартудан һәм, ышанычларын акламаганлыктан, туганнарымның күзләрендә өметсезлек күрүдән курку.

Мин дәшмим һәм дөреслекне инде күп еллар яшереп саклыйм, шушы еллар дәвамында курку һәм үкенеч хисләре мине чын мәгънәсендә пара-парә телгәли.

Бу курку һәм үкенеч миндә әле дә яши, тик мин хәзер үз хәлемә карата ачыграк була барам. Мин озак вакыт якынлык кылудан тыелырга үз-үземә вәгъдә бирдем. Мин кешеләр тарафыннан тиешле реакциягә әзер түгел идем, тулаем алганда, җәмгатьчелек бу вируска һәм аны тапшыруга карата зур түземсезлек һәм наданлык күрсәтә бит.

## ИҢ МӨҺИМ ТӘҖРИБӘ (УҢАЙ һӘМ ТИСКӘРЕ)

Баштагы берничә ел дәвамында һәм табибларга даими барып тору дәверендә мин җитәрлек дәрәҗәдә сәламәт булып кала килдем. Миңа «җай килде» – вирусның көче бик үк югары түгел иде, һәм мин бернинди дә дарулар кулланмадым. Мин югары иммунитет саклый һәм вирус көчен контрольдә тота алдым. Тәмәке тартуны ташладым, сәламәт туклануга күчтем, чыдамлылыкка йөгерүдә эчке агрессияне чыгару ысулы күрдем. Башта мавыгу гына булган әйберләр нәтиҗәдә минем өчен коткаручы могҗизага әверелде. Мин бервакытта да спорт белән шөгыльләнмәдем һәм, менә үземә нидер таптым, ул яхшы гына килеп чыга башлады. Ул чакта әле мин йөгерүнең тормышымны үзгәртеп кенә калмыйча, аны коткарачагын белми идем.

2012 елда мин үземнең беренче «Tough Mudder» йөгердем. Бу тәҗрибә миңа шуңа охшаш уннарча ярышта катнашырга этәргеч бирде – 2014 елга мин «Tough Mudder»ның 5-6 йөгерешен уздым, спартан спринтларында (Spartan Races), хәрби марш-бросокларда (Warrior Dash), берничә 5000 метрга йөгерүдә катнаштым, хәтта апам белән 5000 м га күңелле гаилә узышларын оештыручы булдым. Ул гына да түгел, дусларым һәм туганнан туган абыем белән команда оештырып, аның составында санап үтелгән кайбер узышларда йөгердем.

2014 ел ахырына мин «World's Toughest Mudder» – чыдамлылыкка 24 сәгатьлек узышта катнашырга әзерләндем. Минем тиешле дәрәҗәдә тренировкалар узарга мөмкинлегем булмады, аның урынына без команда белән, туганнан туган абыемны да кертеп, волонтерлар буларак катнаштык. Өч смена буена мин дөнья элитасына кергән йөгерешчеләрнең карусыз һәм кеше мөмкинлегенең чикләрендә коточкыч шартларда каршылыкларны узуларын күзәттем. Болар барысы да 24 сәгать буе йөгереп һәм туктаусыз. Нәкъ менә шул вакытта мин 2015 елда бу узышны җиңеп чыгачагым турында карар бирдем.

2014 ел ахырында сәламәтлегем начарланып китте. Эштәге стресслар һәм өйдә акча проблемалары минем организмда чагылыш таба башлады. Январьда мин ике ял көне дәвамында өч спартан спринты йөгерергә тиеш идем, әмма минем күкрәгемдә авыртулар башланды.

Бары соңрак кына моның үпкә ялкынсынуының башлангыч стадиясе булуын белдем. Мин йөгердем, әмма миңа бик авыр, читтән күренгәнгә караганда да авыррак иде. Өйгә кайткач, табибка киттем. Анализ нәтиҗәләре тынычландырырлык түгел иде – минем иммун системасы җиңелчә түбән дәрәҗәдән 55 Т-күзәнәк дәрәҗәсенә төшкән, ә вирусның көче “шартлап”, 575 меңгә җиткән. Миндә СПИД иде.

Шул көнне бераз соңрак эштә киңәшмә булды. Берничек тә оеша алмый торган проектка карата озак айлар дәвамында миндә җыелган күңел кайту, хезмәттәшләрнең сүзсезлеге, авыруым аркасында туган физик уңайсызлык тою мине сындырды һәм, мин көчле нотык тотып, ниһаять, калган хезмәттәшләремә дөреслекнең бер өлешен булса да әйтә алдым. Начар эшләре, гамьсезлек һәм бөек эгоизм – бу дөреслекне ишетү аларга рәхәт түгел иде… Нәтиҗәдә мин күпмедер вакытка эшсез калдым.

Тормышымның алдагы чоры минем өчен тагын да тирәнрәк, ягъни төбе булды, аның каравы үземне аңларга вакыт барлыкка килде. Мин гап-гади сайлау алдында калдым – я дәвалана башларга, я үләргә.

Бу этапта минем хәлемнең авырлыгы турында бик азлар гына белде, хәер, һәрвакыттагыча, гаиләмдә мин бу турыда сөйләп тормадым. Дөресен әйткәндә, кайбер кешеләрнең (кем турында әйтүемне алар үзләре беләләр) үз максатларына ирешү һәм «World's Toughest Mudder» да катнашучыларның искиткеч җәмгыятенә керү теләге белән әйткән теге берничә сүз булмаса – бүгенге көндә мин инде исән дә булмас идем.

Тирән рухи төшенкелек халәтендә, мин, кире кагарлар дип курыкканнан, башка йөгерешчеләргә үземнең хәлемне белдермәвем өчен гаеплелек хисен тоюымны искә төшердем. Бу курку урынсыз иде, чөнки йөгереш трассасында башка йөгерешчеләргә инфекция йоктыру мөмкинлеге юк. Шул ук вакытта мин кешенең наданлыгы кайвакыт никадәр көчле булуын бик яхшы аңлый идем.

Аннары башыма каяндыр Facebookка эзләргә бирү уе килде, һәм кинәт ни күрәм: 2013 елда «World's Toughest Mudder» финишында хатын-кызлар арасында иң яхшы вакытны ул мизгелдә инде минем өчен үрнәк булган Деанна Блегг – уңай ВИЧлы хатын күрсәтә. Деанна – теләсә кайсы чарада чын йолдыз, ә ул инде күп еллар ачыктан-ачык чыгыш ясый.

Мине шаккатырганы шул булды: киртәле йөгерешне сөючеләр җәмгыятендә аны кочак җәеп каршы алалар. Дистанциядә кинәт аның кемне дә булса зарарлау ихтималына карата бер начар сүз дә, адресына бер генә тупас комментарий, куралмаучылык юк. Бернинди курку юк. Мин барыннан да артык курыккан нәрсәләр – барысы да ялган булып чыкты. Нәкъ менә шуның аркасында миндә сәламәтлегемне һәм спорт кыяфәтемне кире кайтару теләге туды һәм ныгыды.

Дарулар кабул итүгә күчүне һәм антибиотикларга шактый авыртулы аллергия турында күңелсез яңалыкны кичереп, мин әкренләп үземне яхшырак хис итә башладым. Йөгерү тренировкаларын яңарттым, минем икенче сулышым ачылгандай булды. Команда тупладым, аның составында «World's Toughest Mudder»га теркәлдем, әле тагын ярдәм сорап турыдан-туры Деаннага мөрәҗәгать иттем һәм үземнең тарихым белән уртаклаштым. Нәтиҗәдә, 2015 елны мин «яңадан тудым».

Дөресен әйткәндә, ул вакытта йөгерү тизлегем мине канәгатьләндерми иде, аның каравы мин гомеремдә беренче «World's Toughest Mudder»ны җиңеп чыга һәм тәмамлый алдым.

Тагын да мөһимрәге: барлык ялгышлыкларыма карамастан, үзем өчен моның берниндиі дә үлем карары булмавын аңладым. 24 сәгать эчендә минем командам гомеребездәге иң авыр 168 киртәле 64 км дан артык озынлыктагы полосаны үтеп чыкты.

Шунда мин үземнең уңай ВИЧлы кумирым – Деанна белән йөзгә-йөз очрашу бәхетенә ирештем.

Бер кичне миңа Деанна Казан марафонындагы «Үз-үзеңә ышан» Россия командасы турындагы яңалыкка сылтама җибәрде, бу иҗтимагый башлангычның меңнәрчә кешеләрне инфекциядән коткарырга һәм башкаларга курку тулы тормыштан котылырга ярдәм итәргә сәләтле булуы турында язды.

Һәр көн – яңа старт кебек. Ни дисәң дә, яшәү – искиткеч, нибары бер ел узды, ә мин чынлыкта үлеп терелдем, физик яктан гына түгел, акыл ягыннан да – мин монда, Россиядә, сезгә мөрәҗәгать итәр һәм үз тарихымны сөйләр өчен караңгылыктан яктылыкка чыктым сыман. Әгәр минем тәҗрибәм кемгә дә булса ярдәм итсә, димәк, мин дөньяга нindidер бер яхшылык эшлим. Мин яңа ачышлар һәм яңадан-яңа ачылышлар тулы киләчәккә чын күңелдән ышанам.

Мине «Үз-үзеңә ышан» командасының бер әгъзасы итеп сайлагач (сайласалар түгел), мин көчлелек чагылышы булган кешеләрнең берсенә әйләнәчәкмен һәм шул вакыт битлегемне салачакмын.

2016 ел минем өчен ачылыш елы булачак, мин барлык туганнарыма һәм дусларыма ачылачакмын. Мәхәббәт һәм ярдәм һәрчак янәшәмдә булды – миңа бары аларга йөз белән борылырга тәвәккәллек кенә җитмәде.

# 04



# Сиамсумерлин

Индонезиядән

26 яшь, дистанция 21 км

Мин ВИЧ-инфекция белән 2012 елның августыннан көрәшәм.

Ниндидер бер мизгелдә мин өметемне бөтенләй югалттым. Ә аннары минем тормышымда үзенчәлекле бер кеше – консультант барлыкка килде. Бу хатын-кыз минем туган шәһәрем Макассареның (Индонезия) инфекцион үзәгендә эшли. Ул миңа башка «нормаль» кешеләр кебек яши алачагымны аңларга ярдәм итте. Нәкъ аның белән очрашканнан соң, мин АРВ-препаратлар куллана башладым. Хәзерге вакытта минем сәламәтлегем тәртиптә.

**Мин үземнең уңай ВИЧлы статуста икәнлегемне, доктор белән шәфкать туташыннан кала, беркемгә дә әйтмәдем. Хәзер сәламәт тормыш рәвеше алып барырга тырышам. Ләкин ялганлык йөге мине баса бара, миңа бик авыр. Эш шунда, мин үземнең статусымны яшерәм.**

2015 елның 6 декабрендә мин уйламаган җирдән Макассареда үткәрелгән ярым марафонда (21 км) катнаштым. Мондый аралыкны мин дә сәламәт кешеләр кебек йөгерә алам бит... Моны исбатлау минем үзем өчен бик мөһим иде. Ул көнне 18 км ны үтә алдым, һәм хәзер бу уңышның бик үк начар булмавын аңлыйм. Мин даими рәвештә йөгерергә карар кылдым. Шул көннән башлап, һәр көн иртә белән 10 км йөгерәм. Бу бик тә рәхәт, бик тә күңелле һәм киеренкелектән арыну өчен яхшы.

**Бер вакыт социаль челтәрләрдә Казанда үткәрелә торган марафонда ҮЗЕҢНЕ СЫНА командасы туплануы турында мәгълүмат күрдем. Шул вакыт мин үземә: «Мин даими тренировка ясыйм, спорт белән шөгыльләнәм, 18 км ны инде йөгереп үттем, үземне Россиядә үткәреләчәк ярым марафон дистанциядә сынарга миңа нәрсә комачаулый? МИН ҮЗЕМНЕ СЫНАРГА ТИЕШМЕН!» - дидем. Ә моннан тыш, әти-әниемә барлык дөреслекне дә сөйләргә дип үз-үземә сүз бирәм.**





Минем исемем Сиамсумерлин, дусларым мине Сэм яки Мерлин диләр.

Миңа 26 яшь, мин Индонезиядән. Инде дүртенче ел ВИЧ белән яшим.

2011 елның декабрендә миңа 23 яшь иде. Мин әле генә университетны тәмамладым, һәм туган шәһәремнән илебез башкаласы булган Джакартага – тормышымдагы беренче эш урыны булган шәһәргә күчеп китәргә җыенган идем. Минем өчен бу беренче эш урынына китү генә түгел, ә күпкә мөһимрәк. Мин гомеремдә беренче мәртәбә туган шәһәремне ташлап китәм, беренче мәртәбә самолётка утырам, беренче мәртәбә зур шәһәрдә берүзем яшәргә җыенам... Барысы да минем тормышымда беренче мәртәбә. Мин үз-үземә урын таба алмыйм, ә әти-әнимнең йөзләре минем белән горурланудан балкый, чөнки мин гаиләдән башкалада эшкә урнашкан беренче кеше. Мин яңа тормыштан, биографиямнең яңа этабы башланудан ләззәт кичерәм.

Тормышта барысы да син көткәнчә генә булмый икән. Иң зур авырлык минем яңа эшемдә туды. Мине белемем туры килмәгән бүлеккә билгеләделәр. Мин бөтенләй өметсезлеккә бирелдем. Ә инде алты айдан эштән кудылар, төп сәбәп итеп җыелган балларның уртачага туры килмәве күрсәтелде. Өйдәге тантаналы озатулардан соң, мин үземнең кире әйләнеп кайтуымны күз алдына да китермәдем. Шуңа күрә, билне кысып бәйләп, яңа эш эзләргә керештем. Интернетта һәм газетларда булган вакансияләр турындагы белдерү адресларына үзем турында резюме җибәрдем. Көне-төне, нинди дә булса кадрлар бүлегеннән шалтыратырлар дип, күземне телефоннан алмадым.

Бервакыт шулай көтмәгәндә «Holland America Line» круиз лайнерына экипаж туплануы хакында белдерүгә юлыктым[1]. «Менә ул!», – дигән уй үтте баштан. Барлык тестларны уңышлы үтәсе иде дә, чит илдә эшлисе иде. Менә әти белән әни шатланачаклар! Икенче көнне иртән мин кадрлар агентлыгына документларымны илттем. Сайлап алуны түләүсез булыр дип уйлаган идем, әмма миңа административ хезмәт, сертификация һәм медицина комиссиясе өчен шактый гына түләргә туры килде. Ләкин кем тәвәккәллек итми, шул җиңми. Шулай бит? Кыскасы, мин бу процессларны үтү өчен барлык булган акчамны чыгардым. Беренче этап әңгәмә иде. Мин аны бик яхшы үттем. Аннары инглиз телен белүне тикшерүгә стандарт тест булды. Мин анысын да җиңел генә башкардым. Медкомиссия генә калды.

2012 елның июле. Клиникага кадәр автобус белән 1 сәгатькә якын барга-

1 Holland America Line – Австралия компаниясе, диңгез круизы судноларыя иясе һәм операторы

ымны хәтерлим. Канны берничә анализга, шул исәптән ВИЧ-ка да тапшырырга кирәк иде. Шуннан мин залдагы башка килүчеләр янына барып кушылдым. 1 сәгать үтте, кешеләрнең күбесе инде таралды. Мин берүзем япа-ялгыз калып, сабыр гына анализ нәтиҗәләрен көттем. 3 сәгатьтән соң, залга лаборант чыкты һәм минем фамилияне атады. Мин аның каршысына барып бастым, ә ул миңа никтер бик текәлеп карый башлады. Нәрсәдер тәртиптә түгел иде. Ул, анализ нәтиҗәләрен алу өчен, иртәгә килергә кушты, минем кан үрнәкләрен тагы 2 мәртәбә тикшерәчәкләрен әйтте.

Икенче көнне иртә таңнан мин инде клиникада идем. Тизрәк анализ нәтиҗәләрен һәм медкомиссиянең уңай бәяләмәсен кулыма аласы килде. Мин инде үземне диңгез киңлекләрен айкаучы шәп круиз лайнерында итеп тоя идем. Аляска һәм Канада ярлары табигать күренешләрен күз алдыма китердем, гаҗәеп матур тәэсирләрдә ләззәтләндем. ә аннары үземнең фамилиямне ишеттем һәм табиб бүлмәсенә таба киттем. Ул миңа күзләрен тутырып карады да, көтеп торырга кушып, бүлмәсеннән чыгып китте. Табиб бик озак булмады, ә кире әйләнеп кергәндә аның йөзендә кызганулы караш катып калган иде. Әлбәттә, ул минем белән сөйләшүгә тиешле профессиональлек күрсәттергә теләде. Ләкин аның йөзеннән мин инде нииндидер начар хәл булуын аңладым. Башта миңа берничә гап-гади сорау яңгырады – каян мин, нәрсә белән шөгыльләнәм, дусларым бармы, җенси тормыш белән яшимме, презервативлар кулланаммы… Аннары гына клиниканың минем анализларны беркөн алдан бирә алмавын, минем канымда инфекция табылуын һәм шуңа күрә өстәмә 2 анализ ясауларын хәбәр итте. Хәзер инде алар тулысынча ышана – миндә ВИЧ.

Алдагы ун секунд эчендә мин сүзсез калдым. Табиб әйткән сүзләрне әкрен генә кабатлый-кабатлый аңа карадым. Ишеткәннәргә ышанмадым, моның нииндидер хата, мәгънәсезлек булуына үземне ышандырасым килде. Табиб нәрсәдер сөйләвен дәвам итте, ә мин берничек тә аңыма килә алмыйм. Бераздан мин ачык итеп аның тавышын ишеттем: «Сез кайгырмагыз. Хәзер шундый дарулар бар, сез тынычлап ун ел яши алачаксыз». Минем күкрәгем кысылды, һава җитми башлады. Мин аздан гына шунда – бүлмәдә үк аңымны югалтмадым. Димәк, болар барысы да дөрес! Мин сабый бала кебек елый башладым. ә табиб миңа хатны күрсәтте. Анда түбәндәгеләр язылган иде: «Без Сиамсумерлинны круиз компаниясенә эшкә алырга тәкъдим итмибез». Кыска һәм аңлаешлы… Хатта бернинди тәфсиллек юк, ләкин барысы да аңлашыла: бу эшне мин күрмиячәкмен, чөнки миндә – ВИЧ. Мин клиникадан бик гарьләнеп чыктым, әйтерсең мине пычрак белән коендырдылар. Автобуста тәрәзәгә текәлеп утырганда битемнән туктамыйча күз яшьләрем акты. Кешеләр миңа сәерсенеп карыйлар, әмма миңа барыбер… Хәзер ничек яшәргә инде? Эшне мин мәңге тапмаячакмын, өйгә кайтудан мәгънә юк – эти-әнием бик дини һәм иске карашлы кешеләр, ВИЧ турында ишетсәләр, алар миннән бөтенләй баш тартырлар. Бу авыру хакында мин ул вакытта бик аз белә идем, бары сәламәтлек өзлеккәндә үлем куркынычлыгы артуыннан хәбәрдар идем. Чыннан да, мин Джакартада үләргә теләми идем.

Мине беренче эштән туры килми дип кусалар, икенчесенә ВИЧ-инфекция аркасында алмадылар. Я Хода, инде хәзер нишләргә? Бөтен тормышым, яшәвем чәлпәрәмә килде. Миңа бик ямансу һәм куркыныч иде. Бу хәбәрне кем дә булса ишетер дә, эти-әниемә, туганнарыма сөйләр дип бик курыктык. Ни өчендер ныклап авырып китәрмен дә, шушы фатирда үләрмен кебек тоела иде. Минем бик тә, бик тә өйгә кайтасым килде.

Шул ук кичне туган шәһәремә оча торган соңгы рейс самолётка утырдым. Очышны ике сәгатькә тоткарладылар. Хәтерлим, миңа кинәт нәрсәдер булды. Аэропорт бәдрәфенә бикләнеп, егерме минут дәвамында кулларымның калтырануын басарга тырышуым уңышсыз иде. Бер ара үземнең пычрак бәдрәф идәнендә ятуымны аңладым. Мин торып баса алмыйм. Бөтен тәнемдә хәлсезлек. Нииндидер көч аркасында тордым һәм самолётка кадәр бардым. Самолётта мине кабат калтырата башлады. Шул вакытта берәрсе ярдәм итсә ярар иде, дип теләдем! Ләкин төн уртасы, күрше утыргычлардагы кешеләр тирән йокыда иде. Мин стюардессадан аспирин төймәсе сорадым, ләкин аңарда бернәрсә дә юк иде һәм үземне бер стакан җылы су белән тынычландырдым. Аэропортта такси тоттым, ләкин аның да тәрәзәсе ватык булыпчыкты, юлда бик нык өшедем.

Кабат өйдә булу бик рәхәт, әмма мине үземнең хәсрәтем турында эти-әнигә сөйләргәме, юкмы дигән сорау борчыды. Алар бик дини кешеләр, һәм мин аларның каушавын, ачуын һәм куркуын, әтинең миңа кул күтәрүен, әнинең барлык күршеләргә сөйләвен – барысын да күз алдыма китердем. Безнең шәһәребез бик кечкенә, һәм мин котылгысыз рәвештә бөтен халык тарафыннан келәйммәле булачак идем. Әти-әнием миннән баш тартачаклар иде, күршеләрне әйтеп тә тормыйм. ВИЧ аларның һәммәсе өчен (ул вакытта минем өчен дә) нииндидер бик куркыныч һәм хурлык саналган нәрсә иде. Мин үземнең диагнозым турында беркемгә дә сөйләмәскә карар кылдым.

Ләкин килер бер көн, мин йөземдәге масканы салып ташлаячакмын.

## КҮҢЕЛГӘ АВЫР ХАТИРӘЛӘР

**1. CD4 күзәнәкләренең 300дән югары булган дәрәҗәсендә АРВ-терапиянең үтемле булмавы.** Күрше шәһәрдә бик яхшы бер клиника бар, мин аны интернеттан таптым. Уңай ВИЧлы пациентларны инфекцион үзәктә кабул итәләр. Мин анда 2012 елның июледә бардым һәм CD4 күзәнәкләре дәрәҗәсен тикшерү өчен анализ тапшырдым. Анализ 375 не күрсәтте. Миңа бушлай АРВ-терапия алу өчен әлеге күрсәткечнең тагы да түбәнрәк кирәк булуын әйттеләр. Сәламәтлек саклау министрлыгының барлык клиникаларга таратылган нормативлары буенча, түләүсез препаратлардан бары тик CD4 күзәнәкләре дәрәҗәсе 300дән ким булганнар гына файдалана ала икән. Бу нисбәттән бәхәсләшүем бернинди дә нәтиҗә китермәде. Миңа препаратлар бирмәделәр.

**2. Температура.** Өйгә бик төшенке күңел белән кайттым. Ни өчен? Нәрсәгә? Нәкъ шушы стресслы халәт аркасында миндә бизгәк башланды, дип уйлыйм. Мин хастаханәгә эләктем. Һәр иртәдә тирләп чыгудан урын-җирем юешләнеп уянам, бөтен тәнем калтырана.

Төннәрен хәлем тагы да авырлаша – миңа гел бер төсле куркыныч төш керә: менә мин үләм икән, авызымны кычкырыр өчен зур итеп ачам, әмма бер аваз да чыгара алмыйм... Антибиотиклар әкренләп үз эшен эшләде – ике атнадан мин аякка баса башладым.

**3. Рәхимсез мөнәсәбәт.** Өйгә кайту белән анализлар тапшырырга киттем. Бу юлы CD4 күзәнәкләренең дәрәҗәсе 273кә төшкән иде. Бу – АРВ-терапияне бушлай алу мөмкинлеге булачак дигән сүз, ләкин миңа барыбер табиб юлламасы кирәк иде. Мин консультациягә язылдым. Табиб йөклелекнең 5нче яки 6нчы аенда булган хатын-кыз иде. Ул мине дусларча якын итеп каршы алды, әмма статусымны белүгә үк, аның бөтен төс-кыяфәте үзгәрде. ВИЧны ничек эләктерүем турында сорашты, һәм кинәт миңа төрле гаепле сүзләр белән ташланды! Аның ачулы нотыгында «син мондый тормыш рәвешең белән уңай ВИЧ-статуска лаек!» фикере яңгырады. Мин дәшмәдем, ә ул сөйләде дә сөйләде. Ул миңа тиздән син акылдан шашачаксың, белә торып кешеләргә вирус йоктырачаксың һәм алардан шулай итеп үч ала башлаячаксың, дип юрый башлады. Бу сүзләр минем башыма сыймады. Ничек инде табиб шундый сүзләр сөйли ала? Мин бит аңардан, АРВ-препаратлар алу өчен, юллама гына сорарга теләгән идем... Ул катгый рәвештә баш тартты. Иң куркынычы шул иде: ул минем белән бик нык кычкырып сөйләште, хәтта акырды һәм бу сөйләшүне коридорда торучылар барысы да ишеттеләр.

Ишектән чыгуга минем яшьтәшем булырлык берничә стажерның карашы белән очраштым. Җанымда ярсу һәм гарьлек туды, ләкин барыннан да авыррагы – ялгызлык хисе. Бүгенге көнгә кадәр бу табиб ханымның миңа ни өчен шулай ташланганын аңлый алмыйм. Бәлки мин аның тормышында очраган уңай ВИЧлы беренче пациент булганмындыр һәм ул миннән курыккандыр? Аның йөкле булуы да ВИЧ-инфекция йоктырудан куркырлык иде шул... Әлбәттә, болар барысы да фаразлар гына.

Ләкин мин шунысын ачык беләм: табиб үзен алай тотарга тиеш түгел. Аның миңа мөнәсәбәте рәхимсез иде.

## ШАТЛЫКЛЫ ХАТИРӘЛӘР

**1. АРВ-препаратлар кабул итә башлыйм.** АРВ-препаратлар алырга юллама язган табибны шатлыгымнан кочаклап алдым. Соңрак клиникада препаратларны кабул итү схемасын аңлаттылар: гомернең ахырына кадәр көненә өч төймә эчәргә кирәк. Шушы өч төймәдә минем бөтен яшәешем.. Башта мин даруларның тискәре тәэсире белән бәрелештем: мине һәрвакыт, хәтта йоклаганда да бөтен тәнем буенча көчле кычыту җәфалады. Табиблар моны «дәвалау схемасы эшли башлады», дип аңлаттылар. 1 айдан соң әлеге кычыту булмаган да кебек иде. Мин препаратлар кабул итүне дәвам иттем һәм һәр ярты ел саен CD4 күзәнәкләренең дәрәҗәсен тикшерү өчен анализлар тапшырам. Күзәнәкләр дәрәҗәсе кимүгә таба баргач, хәлем дә яхшыра иде. Мин терелә башладым, үземдә көч артканын сиздем.

Әкренләп кабат тормышка кайта башладым. Үз шәһәремдә эш эзләдем һәм финанс компанияләренең берсендә эңгәмә үттем. Хәтерлим, анда да медкомиссия үтәргә кирәк иде. Миннән кан анализы алдылар. Мин куркуга төштем: тагы шул ук хәлләр кабатланса?

Каяндыр, Индонезия хөкүмәте пациентларны ВИЧка мәҗбүри тикшерү үткәрүне тыю керткән, дигән хәбәрне укыдым. «Минем ризалыгымны сорамаганнар икән, димәк ВИЧка канны тикшермәячәкләр», – дип уйладым. Шулай килеп чыкты да. Медкомиссия мине сәламәт дип тапты... Аллага шөкер! Мин

әлегәчә шушы компаниядә эшлим. Эшем миңа көндәлек стресслардан арынырга ярдәм итә. Минем өчен матур тормыш кагыйдәләре: яхшы тукланырга, вакытында йокларга ятырга, сәяхәт итәргә һәм АРВ-препаратларны даими кабул итәргә.

**2. Бәйсез яшим.** Абыем өйләнгәч, әти-әни йортында тыгызрак була башлады. Мин моннан күчеп китәргә һәм мөстәкыйль тормыш башларга кирәклеген аңладым. Башта авыррак иде. Эш хакы бик аз, фатир арендасына күп сумма китә, акча очын-очка ялгарлык кына иде. Ләкин мин аякка бастым. Хәзер үз фатирымда яшим. Күп эшлим, даими рәвештә спорт залына йөрим, дусларым белән аралашам. Ләкин күңелнең бер читен кайвакыт ялгызлык хисе өшетә, бу элеккегә караганда сирәгрәк, әлбәттә. Ничек кенә булмасын, мин үземне бәхетле дип саныйм.

Узган елның декабрендә (2015) дустым мине ярым марафонга чакырды. Нишләп әле бармаска? Иске елны озату өчен менә дигән мөмкинлек! Мин 21 км аралыкта йөгерү өчен регистрация үттем, ләкин 18ен генә үтә алдым...Нинди гүзәллек! Искиткеч трасса – урман, дөге кырлары, ямь-яшел үрләр... Йөгерешчеләр арасыннан берсе хәтеремдә калган. Ул – бик күп төрле йөгерешләрдә катнашкан чын профессионал. Шушы үзе әзерлекле , үзе сәламәт спортчы 10 км га гына чапты, ә мин үземнең уңай ВИЧ-статусым белән аңа караганда ике мәртәбә күбрәк араны үтә алдым! Димәк, мин көчлерәк! Мине үзем өчен зур горурлык хисе чолгап алды.

Нәкъ шушы ярым марафон аралыгында мин беренче мәртәбә шуны анык аңладым: ВИЧ – ул бары киләймә генә. Әйе, дарулар әлегә уйлап табылмаган. Ләкин АРВ-препаратлар белән безнең күпчелегебез, башка гади кешеләр кебек үк, тулы тормыш белән озаграк яши ала.

**3. Киләймәгә - юк!** Ничектер шулай очраклы рәвештә уңай ВИЧлы һәм тискәре ВИЧлы ике кеше арасындагы кайнар бәхәскә туры килдем. Һәм шунда кырыс кына бер кеше миңа фикеремне әйтеп бетерергә ирек бирми, гел аяк чала. Ул судья кебек үзен бөтен нәрсәне дә беләм дип уйлый һәм башкаларга сүз әйтергә дә бирми. Мин, гомумән, аның кебек тар карашлы, надан кешеләр белән бәхәскә кермим. Ләкин шул вакытта мине нәрсәдер аңа борылып әлеге сүзләрне әйтергә этәрде: «Сез ялгышасыз. Мин үземне каргалган дип санамыйм. Мин үз статусым турында хәлем бөтенләй үк начарланганчы белдем. Әйе, бу яктан мин уңдым! Бәлки миңа шулай насыйп булгандыр? Бәлки миңа карата Ходайның язган тәкъдире шундыйдыр?

Ә Сезнең үзегезгә килгәндә? Сез нәрсә, барлык йөз процент очракта да презерватив кулланасызмы? Сез бер мәртәбә дә наркотик кабып карамадыгызмени? Сез үзегезнең гөнаһсыз булуыгызга инанасыз икән, мин сезгә каршы чыгам – хәзер үк ВИЧка тест үтегез! Миңа карагыз. Мин ВИЧ белән инде өч ел яшим... Миңа уңыш елмайды! Безнең илдә пациентларга АРВ-препаратлар бушлай бирелә! Мин ул препаратларны һәр көнне кабул итәм. Үземне бик яхшы хис итәм. Мин үз авыруымны кешечә яшәү өчен киртә дип уйламыйм. Ә киресенчә, мин бик тә уңдым, Ходайның юллары акыл ирешмәслек».

Уйламаганда хәлем начарланырга һәм мин үләргә мөмкин икәнлегең яхшы аңлыйм. Ә нәрсә, «нормаль» кешеләрдә дә бу шулай түгелмени? Алар да бит үләләр, без моны көн дә күрәбез: картлыктан, авырулардан, автомобиль аварияләреннән, үз-үзләренә кул салулардан – төрле сәбәпләр белән.

Мин нәрсә... мин үземне ВИЧтан исән чыгучы, аны җиңүче дип саныйм. Мин дә башкалар шикелле үк яши алам: эшкә бара алам, спорт белән шөгыльләнә алам, сәяхәт итә алам, дога кыла алам, дуслаша һәм ярата алам. Сез мине яманларга тиеш түгел.

Әйе, үземне кызганган чакларым була. Әгәр миңа кире үткәннәргә кайту шансы бирелсә... Мин бернәрсәне дә үзгәртмәс идем. Үткәндәге эш-гамәлләрем миңа сабак бирде – ул мине кайбер нәрсәләргә өйрәтте.

Ә тагын ул мине ҮЗЕҢНЕ СЫНА Казан марафоны командасына китерде.

Ходайның миңа язган тәкъдире шундый. Нәрсә генә эшләсәм дә, мин көчемнән килгән һәр нәрсәне үтәргә тиеш. Минем гомерем, башка кеше гомере шикелле үк, кабатланмас, серле һәм кадерле.



БИШЕНЧЕ БӘЯН

# 05

# Евгений

Орёлдан, Россия

39 яшь, дистанция 21 км

Мин анализларны сырхауханәдә тапшырдым. Нәтиҗәләр килгәч, табиб «нәрсәдер дөрес түгел» дип, миңа йогышлы авырулар хастаханәсенә юллама бирде. Билгеле, моның СПИД-үзәк булуы турында башыма да килмәде, шуңа күрә бер дә ашыкмадым. Шулай да, бер-ике айдан соң кызыксынып, нәрсәнең «дөрес түгел» икәнен барып белергә уйладым. Бары чиратта торганда гына монда җыелучыларның күбесе шактыйдан наркотиклар куллануын сиздем. Тәмәке тарту бүлмәсендә бер егет бөтенләй минем аңымны алды: «Беләсеңме, миндә СПИД», – дип кенә әйтте ул. Ә минем соң чиккәчә нәрсә булуын һәм үземнең ни өчен монда килүемне аңлыйсым килмәде. Кабинетка кердем, табиб бик озак нидер язды. Мин түзмәдем: «Минем анализларда нәрсә дөрес түгел?» – дип сорадым. Шуннан соң нинди дер томан эчендә калуымны һәм шул буталчыклыкта башымда туган «минем беркайчан да балам булмаячак» дигән бердәнбер фикерне генә хәтерлим. Аптыраган хәлдә пәрдә аша табибның: «Сезне җибәрергә мөмкинме?» – дигән сүзләрен ишеттем.

Ике еллап караңгылыкта һәм йокымсыраган халәттә яшәдем, мин бары кайда һәм кайчан үләрмен, мине күмгәндә нинди музыка уйнар, дип кенә уйлый алдым. Ул вакытта минем тормышым мәгълүм мәзәктәгечә иде:

- Доктор, миндә СПИД! Нишлим?
- Ләм кабул итегез.
- Нәрсә? Булышамы?
- Юк. Аның каравы җиргә ияләшә торырсыз.

**Мин һәрчак үлем турында уйлап яшәдем, шул ук вакытта мин аның сәбәбе хакында берни дә белми идем: нәрсә ул ВИЧ, мине шушы дәрәҗәгә китергән әйбернең исеме ничек – мин моны аңламадым. Хәтта ретровируска каршы (АРВ – антиретровирус) терапияне дә җитди проблемалар башлангач кына эчәргә керештем. Ә хәзер төгәл әйтә алам: әгәр шул дәвалануны башламасам, мин бу юлларны яза алмаган булыр идем.**
**ВИЧлы кешеләр миңа моның үлем карары булмавын төшенергә ярдәм иттеләр.**







Бу хәл уңай ВИЧлы кешеләр миңа моның үлем карары булмавын төшенергә ярдәм иттеләр.

Бу хәл уңай ВИЧлы кешеләр өчен үзара ярдәм төркеме барлыгы турында ишеткәч булды. Бу минем өчен өмет чаткысы кебек иде. Бу башкаларның әлеге бәла белән ничек яшәүләре, дөресрәге, үләргә әзерләнүләре хакында белү мөмкинлеге иде. Мин ярты ел дәвамында алар янына барырга хәзерләндем һәм, ниһаять, барып җиттем. Беренче тәэсир: бик сәер кешеләр. Аларның шулкадәр шат күңелле булулары һәм чынлап торып алдагы тормышларына планнар корулары мине гаҗәпкә калдырды. Ул вакытта әле Россиядә һәркемгә дәвалану мөмкинлеге юк иде, шунлыктан аларның ышанычлары һәм өметләре миңа аңлашылмады. Алай гына да түгел, анда беренче тапкыр барганда мин ВИЧны дәвалап булуына да шикләнә идем.

Әмма бу төркем минем бөтен тормышымның астын өскә әйләндерде. Мин ВИЧ белән яшәү мөмкинлеген кабул иттем һәм яңадан әкренләп бәхетле кеше булырга өйрәндем.

Тиздән мин ышаныч телефонында волонтер булдым, бераз соңрак ВИЧлы кешеләргә багышланган журналда эшли башладым. Чынлыкта, «СПИД кризисы» миңа уйланырга, кыйммәтләремне һәм тормышта өстенлек биргән әйберләремне яңадан карарга мәҗбүр итте. Сәер һәм гаҗәп тоелса да, әлеге диагноз аркасында мин чын-чынлап бәхетле кешегә әйләндем һәм менә инде 15 ел дәвамында шундый булып кала бирәм. Мин дә планлаштырам. Картлыгымны уйлыйм… Беләсезме, алдагы пенсияләрен кайгырту минем күпчелек "сәламәт" яшьтәшләремнең башына да килмидер әле.

Мин ВИЧ белән яшәргә өйрәндем һәм, хроник авыруга карамастан, сәламәт булып калу өчен нинди чаралар күрергә кирәклеген беләм.

**ВИЧ әхлак һәм гореф-гадәтләрне белми. Бары тик үз сәламәтлегебезне генә кайгыртсак та, безнең һәркайсыбыз эпидимияне туктата алуын кешеләр онытмаска тиеш. Ә бит күпме кешеләр ВИЧны җитди кабул итми, бу бәла аларны читләтеп узар дип уйлый. Күпчелек шулай фикер йөртә, ә илдә шул ук вакытта миллионлаган зарарлану очраклары теркәлә.**

Минем тормышымда спорт зур роль уйный.

Соңгы вакытта мин спорт белән күп шөгыльләнергә тырышам. Болай, барыннан да бигрәк, мин тонуста калам. Иң мөһиме шул: минем киләчәктәге планнарым сәламәт булганда гына тормышка ашачак. ВИЧ белән сәламәт булганда.

Ничек үземне җиңеп йөгерә башлавымны мин инде хәзер хәтерләмим дә, әмма өч еллап яздан көзгә кадәр өебез янында йөгерәм. Минем өчен йөгерү медитациягә тиң, ул миңа үз-үзем һәм әйләнә-тирә белән гармониядә булырга ярдәм итә. Йөгерү – минем антидепрессантым.

**Марафон турында ишеткәч, шунда ук үземә әйттем: мин йөгерергә тиеш. Шуның өстенә, 10 километр минем өчен проблема түгел. Әмма катнашуымның төп сәбәбе: мин шул рәвешле, кайчандыр минем кебек, үзләрен тереләй күмәргә өлгергән ВИЧлы башка кешеләргә үрнәк була алам.**

Хәзер, ун километр йөгерергә теләгәч, мин аңа фитнес-үзәктә җитди рәвештә хәзерләнә башладым, йөгерү һәм аның техникасы турында күп яңа нәрсәләр белдем. Мәсәлән, элегрәк мин дөрес йөгермәгәнмен икән, хата җибәрмәс өчен, мин фейсбукта үзара ярдәм принцибында эшли торган төркем оештырдым. Хәзер тәҗрибәле катнашучылар киңәше белән хаталарсыз һәм сәламәтлегемә зыян китермичә генә марафонга әзерләнәм, әкренләп ерак араларга йөгерергә күнегәм. Шул ераклыкларның берсе – минем тормышым.

Бу дистанция йөгерүемнең максатына әверелде. Мин аны үтеп чыгармын дип ышанам. Нәкъ менә теләсә кайсы проблемаларны һәм киртәләрне җиңә алуымны сизү, теләсә нинди максатларны тормышка ашыра алуымны тою мине чиксез бәхетле кеше итә.

Мин бәхетле кеше, чөнки бөтен әйберем дә бар, ә инде хәзерге вакытта нәрсәм дә булса юк икән, ул әлбәттә булачак, бары теләргә генә кирәк.

Синең тормышың ВИЧлы килеш тә начарлыклар белән генә түгел, яхшылыклар белән дә тулы. Кызганыч, миңа ВИЧлы кайбер дусларымны югалтырга туры килде. Әйтергә кирәк, бер дустым катгый рәвештә дәваланырга теләмәгәннән шулай иртә арабыздан китте. Мин, ни тырышып та, дәвалану зарурлыгына аны ышандыра алмадым.

Соңгы сүз итеп, шуны әйтәсем килә: тормышымда нәрсәне дә булса үзгәртергә мөмкинлек чыкса да, мин аны эшләмәс идем. ВИЧ гомеремдә мине тулысынча үзгәртә торган кризис булды. Никадәр сәер яңгыраса да, шушы авыру аркасында мин чын бәхетле кешегә әйләндем.

# 06



# Жандос

Казахстаннан

24 яшь, дистанция 10 км

Башка барлык кешеләрнеке кебек үк, минем тормышымда күңелсез хәлләр дә, яхшылары да булды.

**Күңелсезеннән башлыйм.** ВИЧлы кешенең тормышында иң караңгы мизгел нәрсә булуы хакында уйлап, озак баш ватарга кирәкми.

ВИЧ йоктыруым турында белү тарихы минем өчен бик авыр. Ничек кенә сәер тоелмасын, ВИЧ дип аталган бу упкынга төртеп төшерерлек нәрсә дә булса эшләмәгәнгә күрә, бу аеруча кыен.

Мин наркотик матдәләр куллану түгел, аларның нинди кыяфәттә булуын да белмим. Минем принципларым туйга кадәр җенси мөнәсәбәткә керүгә каршы килә.

Минем принципларым туйга кадәр җенси мөнәсәбәткә керүгә каршы килә. Минем тормышым йөз меңнәрчә кешеләрнекеннән берни белән дә аерылмый: мәктәпне тәмамладым һәм медицина университетына керү нияте белән Караганда шәһәренә килдем. Уку елы ахырында мин донор булырга карар кылдым. Кан биргәннең икенче көнендә, мин имтихан бирергә чират торганда, кинәт телефоным шалтырады. Миңа канымда нәрсәдер табылуы һәм СПИД-үзәктә тикшерелергә кирәклеге турында әйттеләр. Мин үземдә ВИЧ-инфекция дип шикләнүләрен белдем. Университетның беренче курсында. Чит шәһәрдә. Туганнарымнан һәм якыннарымнан еракта. Ул көн ике ел ярым дәвам иткән аяныч фильмның беренче кадры булды.

Ни өчен бу хәл килеп чыкты? Мин нәрсәне дөрес эшләмәдем? Инде әйткән идем: минем яшәү рәвешем ВИЧ белән зарарлану ихтималын юкка чыгара, әмма, ничек кенә булмасын, бу хәл килеп чыкты. Бердәнбер мөмкин булган аңлатма – ниндидер гамьсезлек. Гадәти игътибарсызлык. Кеше факторы. Бу, мисал өчен, мин мохтаҗ донор үзәгендә кан биргәндә дә булырга мөмкин.

Мин курыктым. ВИЧ турында уйларга, искә төшерергә, фикер йөртергә курыктым. Актык көчем белән бу турыда онытырга, үз куркуларым эчендә юкка чыгарга тырыштым. Курку башка хисләрнең барысын да тыйды. Мине бердәнбер тынычландырган нәрсә – тизрәк өйгә кайту һәм мәңгегә йокыга талу. Тик курку анда да җелегемә үтте – төн уртасында уянып китәм дә, үлememне күз алдына китереп, елыйм да елыйм. Шул рәвешчә, үләргә әзерләнә-әзерләнә, әҗәлнең котылгысызлыгы белән килештем.

Әти-әнием белән телефоннан сөйләшкәндә, әниемнең «Йә, улым, анда синең бар да яхшымы?» дигән соравына аннан ярдәм сорап кычкырасым килә иде. Бөтен куркуымны эчтән чыгарасым килә иде. Алга таба ничек яшәргә кирәклеген белмим, диясем килә иде. Әмма булдыра алмадым. Мин гаиләдә өлкән ир бала, гомер буе әти-әниемә терәк һәм энемә үрнәк булган, шундый мөстәкыйль һәм уңышлы кеше – ничек инде мин гаиләмә үземнең бәхетсезлегем турында әйтә алыйм? Ничек мин аларның өметләрен өзим? Һәрвакыт, трубканы кысып, чыбыкның икенче очындагы әниемнең тавышын тыңлаганда, мин куркуымнан тынсыз кала идем. Мин әти-әнием алдында дәрәҗәм төшүдән курыктым. Мин аларны уңайсыз хәлдә калдыра алмый идем һәм моңа хакым да юк. Әти-әниемнең мондый яңалыкны күтәрә алмасларын мин төгәл белдем, шуңа күрә ике ел ярым дәвамында үземне тыеп яшәдем.

Бу еллар эчендә кичергәннәрем вакыт-вакыт күңелемне тирән яралый иде. Минем кабатлануыннан шулай каты куркырга мәҗбүр иткән ачы тәҗрибәм бар иде инде: бервакыт диагнозым турында янына әледән әле барып йөргән якын кардәшем белде. Шулай, көннәрдән бер көнне, мин аның янына килгәч, урамда йөрергә чыгып киттем, ә ул мин юкта, ни сәбәпледер, сумкамдагы әйберләр белән кызыксынган. Анда төймәләрне табып алган да интернеттан аларның нәрсә икәнен һәм нинди кешеләр, нәрсәдән куллануын белгән. Мин кире кергәндә сумкам бусага төбендә тора, ә өйдә тырышып-тырышып җыештырырга керешкәннәр. «Нәрсә булды?» дигән соравыма җавап кыска булды: «Аңла, минем балаларым бар, ә синең чирең ак тап булачак… Бу адресны онытǃ» Ул көнне үпкә яшьләре дә, инде гадәткә кергән үз-үземә кул салу турындагы уйлар да булды – тормышымның калган өлешенә ниндидер рәхимсез давыл ябырылды, барысы да яңадан җимерелде дә җимерелде. Туганымның миңа ничек тә булса аңлатырга мөмкинлек тә бирмәве үпкә ачысын тагын да көчәйтте, без аның белән бүгенге көнгә кадәр аралашмыйбыз.

Курку. Курку, курку, курку – менә нәрсә иде тормышымның юлдашы. Нәрсәдән куркуымны да белмим: котылгысыз үлемнәнме, әллә, кешеләр минем ВИЧ статуслы икәнемне белгәч нәрсә әйтүләреннәнме?

**Әмма, әйткәнемчә, тормышта кайгысы да, шатлыгы да була.**

Университетта укый башлавымның беренче көннәреннән үк миңа төркемебездәге бер кыз ошый иде. Тиздән без бик якынайдык – безнең уртак әйберләребез күп, әмма бер-беребезне туйдырылык дәрәҗәдә түгел. Безгә бергә бик рәхәт, тик беренче курс ахырында миңа ВИЧ диагнозы куйдылар. Монда да куркуым үзенекен итте: мин аны куркытудан шикләндем һәм әкренләп аннан читләшә башладым. Һәм без инде мөнәсәбәтләре дәресләр алдыннан баш кагышудан узмаган укудагы танышларга әйләндек.

**Ул миңа һаман да бик нык ошый, тик аның белүенә юл куя алмыйм, аның мине нәрсә борчуын белергә теләү омтылышларыннан кача идем.**

Икенче курста кызыклы бер хәл булды: иммунологиядә ВИЧ темасын үткәндә мин түзмәдем, башка студентлардан «Яраткан кызыгызда яки егетегездә ВИЧ тапсалар нишләр идегез?» дип сорадым. «Алга таба мөнәсәбәтләрегезне саклый алыр идегезме?» дидем. Җавапларын түземсезлек белән көтсәм дә, ул ачык иде: юк, берәүнең дә тормышын уңай ВИЧлы кеше белән бәйлисе килми.

**Иң гаҗәпләндергәне миңа ошаган кызның җавабы иде: «ВИЧ – араларны өзү өчен сәбәп түгел, җитди хисләргә зуррак киртәләр кирәк». Бу җавапка каршы елмаюымны һәм кызарып китүемне бүгенгәчә хәтерлим, шул мизгелдән аңа серемне сөйләү турындагы зәгыйфь фикер башымнан китмәде.**

ВИЧ һәм мөнәсәбәтләргә карата позициясен белгән хәлдә, ничә мәртәбәләр аның реакциясен күз алдыма китердем, әмма кыюлыгымны җыеп, ничек бар шулай сөйләр өчен миңа тагын ике ел вакыт кирәк булды. Мин аны еракта калган бер кайгысыз беренче курс турында «иске дусларча» берәр җирдә сөйләшеп утырырга чакырдым, ә аның белән бергә уздырган көннең ахырында очрашырга тәкъдим иттем. Һәм шунда үземнең уңай ВИЧлы булуым турында әйттем. Аның реакциясе минем өчен ачыш булды. Ул бөтенләй диярлек гаҗәпләнмәде. Барысын да тыныч кына кабул итте һәм бердәнбер соравын бирде: шушы еллар дәвамында авыруым турында сөйлисе килмәгәнгә аның белән аралашудан качканмынмы? Минем «Әйе» дигән җавабыма ул көлеп җибәрде. Әлбәттә, ул лекциядә мин сорау биргән вакыттан ук барысын да сизенгән. Менә шул, без инде өченче ел очрашабыз, киләсе 2017 елда өйләнешергә уйлыйбыз. Ул минем ышанычым һәм терәгем. Аны тапканнан соң миңа яшәве җиңелрәк була башлады.

Шулай ук мин, кыюлыгымны җыеп, ВИЧ белән яшәүчеләргә үзара ярдәм төркеменең җыелышына барган көн өчен Ходай тәгаләгә рәхмәтле. Мине анда ике ел дәвамында чакырсалар да, качып йөрдем. Төркемдә уздырган беренче көннән соң ук мин үземнең ялгыз булмавымны аңладым. Мин ялгыз түгел! Әкренләп мин төркемдә активрак катнаша башладым һәм төркемнең үзәгенә әверелүемне сизми дә калдым. Башта консультант булып эшләдем, эшемне лаеклы итеп башкару өчен күп укыдым һәм ышанычлырак мәгълүматлар җыйдым – медик буларак миңа моны күзәтү икеләтә мавыктыргыч булды. Оратор буларак талантым да ярдәм итте. Өлкәдәге СПИД-үзәк базасында оештырылган «Өмет» иҗтимагый оешмасында консультанттан алып пациентлар советы рәисенә кадәрге юлым шулай үтте. Мин дәрвиш булып яшәүдән туктадым, иҗтимагый тормыш алып бара башладым. Миңа ВИЧлы кешеләрнең төбәк һәм милли ассоциациясе зур ярдәм күрсәтте. Әйе, шундый ассоциацияләр дә була – алар миңа һәм уңай ВИЧлы башка кешеләргә тормышны билэп алган куркудан котылырга булышалар. Шулай мин СПИДны дәвалау буенча Европа төркеменә укырга кердем (EATG Training Academy STEP - UP).

Миңа яшәү ошый башлады. Мин инде үз статусымнан курыкмыйм. Минемчә, мин аны үземә һәм башкаларга файдага борам. ВИЧ аркасында мин кешеләргә файда итәм: укыйм, ВИЧ профилактикасы буенча тренинглар үткәрәм, үз төбәгемдәге ВИЧлы кешеләр оешмасын берләштерү буенча эшлим. Хәзерге вакытта минем планнарым зурдан, иҗат итәсем һәм кешеләргә булышасым килә, озак яшисем һәм бәхетле буласым килә!

Консультант булып эшли башлаганда мин үзем өчен кешеләр белән аралашу шатлыгын ачтым һәм хәзергәчә моны яратып эшлим. Һәр тарих – авырту катыш, күз яшьле һәм югалтулар тулы тәҗрибә. Әле дә хәтеремдә: бер көнне минем яныма яшь кенә йөкле бер кыз килде. Аның иммун системасы бик зәгыйфь һәм табиблар аңа йөклелеген (12 атналык) өзәргә киңәш биргәннәр. Кыз сайлау алдында калган. Интернеттагы һәртөрле форумнарны укый-укый, ул гаҗиз булган. Ул да курка иде. Акылы һәм табиблар баладан котылырга куша, тик эчендә нидер аны бу эштән тыя; үзенең йөклелеген саклыйсы һәм баласын табасы килә. Без бергәләп төрле киңәшләр укый башладык, мин кызга йөклелеген өзәргә тәкъдим иткән табиб белән үзем сөйләштем.

Дөресен әйтим, аның дәлилләре чиста фаразлардан гыйбарәт иде. Ул бары үз өстенә җаваплылык алырга, аны кыз белән бүлешергә теләмәгән. Бәхеткә, кыз үзе йөклелеген сакларга карар кылган һәм мин күпмедер вакыт аңа ярдәм иттем. Төрле сәбәпләр аркасында, без бер-беребезне күздән югалттык, ел дәвамында мин үзара ярдәм төркемендә катнашучылардан аның турында нәрсәләрдер ишеттем, тулаем алганда элемтә өзелде. Кинәт, бер елдан соң без СПИД-үзәктә очраштык, аның янәшәсендә кечкенә кызы иде. Кыз үзе дә үзгәргән: күренеп тора, тормышы җайланган. Мин аны бәхетле итеп күрүемә бик шат идем. Баланы инде исәптән төшергәннәр – кызчыкта ВИЧ табылмаган, аңа бер яшь тулган.

Мин аның өчен табиб буларак та, аның кебек үк ВИЧ белән яшәүче кеше буларак та шатландым. Куркуын җиңеп, бәхетле булырга өйрәнгән кеше буларак сөендем.

# Соңгы сүз

Төрле кешеләр. Төрле язмышлар. Бер яктан караганда, алар арасында урталыклар юк диярлек. Юк диярлек… Гадәти шартларда алар, бер-берсе белән сөйләшер өчен, кызыклы темалар да тапмаслар иде, мөгаен. Алай да, аларны – Казаннан йөз, хәтта мең чакрым ераклыкта яшәгән кешеләрне – 2016 нчы елның 15 нче маенда нәрсәдер бергә җыелырга мәҗбүр иткән. Акча түгел. Дан-шөһрәткә сусау да түгел. Эч пошу да китермәгән аларны монда. Алар СПИДтан үлгән кешеләрне халыкара искә алу көнендә 2016 нчы елгы Казан марафонында "ачык йөз" белән катнаштылар. Максатлары – **ВИЧ белән авыручы кешеләрнең башкалардан аерылып тормавын ассызыклау.**

Әлеге кешеләрнең кайберләре күп еллар дәвамында үзләренең авыруларын хәтта туганнары һәм якыннарыннан яшереп торганнар. Моның бердәнбер сәбәбе – башкалар тарафыннан гаепләнү һәм дискриминацияләнүдән курку. Уйланыгыз әле: хәзерге вакытта ВИЧ белән авыручыларга карата тискәре фикердә түгелме Сез?

Укылган бәяннар ВИЧ белән авыручыларга карата гына түгел, үз сәламәтлегегезгә дә мөнәсәбәтегезне үзгәртергә ярдәм итәр дип, ышанабыз без.

***Ихлас күңелдән яңа максатларга ирешүегезне һәм иминлек телибез. «Сәламәтлек саклау өлкәсендә алдынгы технологияләр үзәге» автономияле коммерциясез оешма.***

# Йомгак

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсен күзәтү буенча Федераль хезмәтнең СПИДны кисәтү һәм аның белән көрәшү Федераль фәнни-методик үзәк җитәкчесе, Россия Медицина Фәннәре Академиясе академигы, медицина фәннәре докторы, профессор.

Хәзерге вакытта дөньяда ВИЧ авырулар тарихы 35 елны үз эченә ала, ә Россиядә 2016 нчы ел башында ВИЧ авырулы 1 000 000 нчы кеше теркәлгән. Озак еллар дәвамында ВИЧ белән нигездә халыкның тар даирәсе – наркотик кулланучылар, фахишәләр, тәртипсез тормыш алып баручы ир-атлар гына авырса, соңгы елларда вирус акрынлап җәмгыятьнең барлык катлауларына үтеп керә башлады.

Бу китапка игътибарын җәлеп иткән өлкәннәрнең һәм иҗтимагый тормышта актив кешеләрнең күбесе үз-үзенә: «Бу хәл миңа беркайчан да янамый», - дип әйтсә, бер дә гаҗәпләнмәм. Дөресме?

Котлыйм! Бәяннәрне укыгыз, фотоларны карагыз. Уйланыгыз әле: наданлык һәм курку тудырган тискәре бер тамга безгә көчләп таккан ВИЧ авырулы кешеләрнең кыяфәтләренә охшаганмы аларның йөзләре?

Мин боларны бары тик бер максат белән язам: ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕП ТОРЫГЫЗ – ВИЧ бармы юкмы икәнен ачыкларга тырышыгыз. Ярты елга бер тапкыр. Сәламәтлегегез хакына.

***В. В. Покровский***
СПИДка каршы профилактика һәм көрәш буенча федераль фәнни-методик үзәк җитәкчесе, РМФА академигы, медицина фәннәре докторы, профессор



# Йомгак

Соңгы елларда Татарстан Республикасы территориясендә ВИЧ-инфекциянең яңа очраклары арту темпы саклана һәм якынча бер процент тәшкил итә. Үз вакытында бастырылган әлеге китап битләре аша ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕР командасы әгъзалары тест узарга чакыра. Тест - ВИЧ-инфекциясен кисәтүнең бер төре. Республикада тест узучы кешеләрнең санын 15 ел элек арттыра башладылар һәм, бу халыкның ВИЧ-инфекция белән күпләп зарарлануы шартларында, бигрәк тә хәвеф-хәтәр төркемнәрендә башланды.

Казанны иң югары дәрәҗәдәге спорт чаралары башкаласы итеп тану сәламәтлекне саклауда яңа технологияләр кертүгә һәм аларның үсешенә ярдәм итә. Россиядә уздырыла торган зур спорт ярышлары нәкъ менә Татарстанда беренче тапкыр ВИЧ-инфекцияне кисәтү һәм ачыклау чаралары урыны булдылар. Шулай итеп, Универсиада-2013 һәм Спортның су төрләре буенча дөнья Чемпионаты-2015 кысаларында спортчылар һәм тамашачылар арасында ВИЧ-инфекцияне кисәтү өлкәсендәге төрле алымнар тикшерелде.

2016 нчы елда әлеге искиткеч чараларны Казан марафоны дәвам итүе мине бик шатландыра. Әлеге чара Татарстан Республикасында күп еллар дәвамында тормышка ашырыла торган секторара партнерлыкның уңышлы булуын тагын бер кат дәлилли. Республикада ВИЧ-инфекция таралуына кискен каршы тору мөмкинлекләре уртак тырышулар ярдәмендә арта бара.

***Н. И. Галиуллин***
Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИДны һәм йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш Республика Үзәге җитәкчесе

ПРОВЕРЬ СЕБЯ
TEST YOURSELF

**Публикация распространяется бесплатно.**
Тиражирование любой части публикации возможны с письменного разрешения АНО «Центр передовых технологий в области здравоохранения».

**The publication is distributed freely.**
Replication of any part hereof are subject to a written permission by ANO "Center for Advanced Healthcare Technologies."

Издано в рамках Казанского марафона 2016 - «Проверь себя»
Published within the scope of the Kazan Marathon 2016 -“Test Yourself”

